Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланган презентация

# Каләмне корал итеп...

Каләмне корал итеп...

## Бөек Ватан сугышында катнашкан татар шагыйрьләре

**Презентация авторы Югары Кэминкэ авылы китапханэчесе Зиганшина Люция Әмир кызы**

Бөек Ватан сугышы елларында татар шагыйрьләре, Советлар Союзының барлык әдипләре белән бергә, немец басып алучыларына каршы көрәште, кулларына корал тотып та, каләмнәре белән дә актив катнашты, явыз дошманны Ватаныбыздан куып чыгаруда батырлыклар курсәтте. Киләчәктә әсәрләр, героик саллы образлар тудыру өчен, рухи азык, рухи чыныгу тәрбиясенең югары мәктәбен үтте.

Һәр солдат кебек, шагыйрьләр дә Көнбатыш Европа илләрен гизгән керәшчеләр булдылар. Халыкны явыз дошманга каршы изге көрәшкә чакыру, фашистларның ерткычлыкларын бөтен дөньяга фаш итү, илебез солдаты, тыл батырлары күңелендә җиңүгә ышаныч тудыру, дошманга каршы ачы нәфрәт хисләре уяту эшләре әдипләргә йөкләнгән иде. Алар радиода эшләделәр, патриотик җырлар, шигырьләр, хикәяләр, повестьлар, пьесалар, сценарийлар яздылар. Үз әсәрләре белән күпмеңле армия аудиториясендә, колхозларда, клубларда, госпитальләрдә чыгышлар ясадылар... Фронтта һәм тылда… Көрәшнең алгы сафында һәркөнне алып барылган бу эш безнең күп әдипләребезнең иҗатын күрелмәгән югарылыкка күтәрде.




Нәфрәт көче

ТАТГОСИЗДАТ
1944

“Нәфрәт көче”
альманахының титул бите

Ш.Мөдәррриснең “Тупчы Ваһап”
исемле китабының титул бите


Шәрәф Мөдәррис

Тупчы Ваһап

ТАТГОСИЗДАТ


ВАТАН ӨЧЕН

“Ватан өчен” мисемле
фронт газетасының бер
бите. 1942 ел.

“Фронт намусы өчен” исемле
фронт газетасмының бер бите,
1942 ел.


БЕЗ СУГЫШТА ЮЛБАРЫСТАН КӨЧЛЕБЕЗ,
БЕЗ ТЫНЫЧТА АТТАН АРТЫК ЭШЛИБЕЗ

Сүз - миллионнарча штыклар булып атакага барды;

сүз - артиллерия залпы кебек, куәтле яңгырады: һәркем йөрәгенә үтеп кереп, җиңүнең безнең якта булачагына ышаныч уятты;

сүз - батыр илнең һәр карыш җире өчен канны да, җанны да кызганмыйча көрәшергә, кыю, тапкыр, батыр булырга өндәде;

сүз - пропагандист булды, халыклар арасында дуслыкны ныгыту өчен тырышты.

Татар әдипләрен һәр җирдә: рядовой солдатлар арасында, команда составында һәм, әлбәттә, хәрби корреспондентлар сафында, фронт газеталары редакцияләрендә очратырга мөмкин иде. Алар фронт газеталарының иң актив хезмәткәрләре булды.

**Бөек Ватан сугышы елларында татар телендә уналты фронт газетасы чыга:**





«Ватан өчен» (Төньяк Көнбатыш фронты),
«Ватан намусы өчен» (Беренче Украина фронты),
«Алга, дошман өстенә!» (Калининград фронты),
«Сталин байрагы» (Көньяк фронт),
«Ватан өчен сугышка» (Карелия фронты),
«Фронт правдасы»,
«Ватанны саклауда» (Ленинград фронты),
«Кызыл сугышчы» (Мәскәү хәрби округы),
«Совет сугышчысы» (Өченче Украина фронты),
«Суворовчы»,
«Кызыл Армия» (Беренче Белоруссия фронты),
«Фронт хакыйкате» (Волхов фронты),
«Җиңү байрагы» ,
«Суворовча кысрыклау»,
«Тревога»,
«Сталин сугышчысы».















"Без, Татарстан язучылары, кулларыбызда каләм һәм корал килеш, данлыклы Кызыл Армия сафына кушылырбыз һәм барлык энергиябез, белемебез һәм талантыбыз белән сөекле Ватаныбыз өчен тормышыбызны да кызганмыйча көрәшербез"

("Кызыл Татарстан" газетасыннан. 1941 ел, 25 июнь).

"Кызыл Армия сафына чакырылгач та, төп хәрби эшем белән бергә, Ватан сугышы темасына багышланган әдәби-иҗат эшемне актив дәвам иттем. Бу дөньякүләм тарихи көрәштә үземнең бөтен сәләтем белән совет сугышчыларының батырлыкларын гәүдәләндерергә тырыштым". (Ф.Кәрим)





Бөек Ватан сугышы елларында татар поэзиясе бөтен совет әдәбиятының куәтле һәм бердәм оркестрында үзенчәлекле һәм көчле яңгыраган шигъри авазларның берсе булды.

Татар совет поэзиясенең бу авазы илебез чикләрен үтеп чыкты, бөтен дөнья халыклары йөрәгенә барып иреште. Күпләр яу кырында башын салды, аларның җырлары җиңеп чыкты, дистәләгән еллар үтсә дә, әһәмияте җуелмаслык поэтик җәүһәрләр калды.

*Зәет Мәҗитов*





9MAYA.ru

## Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясендә төп мотивлар:

• көрәшкә өндәү, чакыру (Ә.Ерикәй. “Сугышка, иптәшләр!”);

• илне сакларга ант итү (Ф.Кәрим. “Ант”; М.Җәлил. “Тупчы анты”; М.Хөсәен. “Туган ил өчен”);

• фашизмга нәфрәт (К.Нәҗми. “Фашизмга үлем!”; Ә.Исхак. “Канга – кан!”);

• туган җир, кадерле кешеләр белән саубуллашу (Ш.Маннур. Саубуллашу җыры”; Г.Кутуй. “Озату җыры”; К.Нәҗми “Озату”);

• фронт вакыйгалары, солдат батырлыгы, уй-хисләре (Ш.Мөдәррис. “Землянкада”; С.Хәким “Хат”; Ә.Фәйзи. “Фронт юлында”);

• тылдагы хатын-кызларның тырыш хезмәтен күрсәтү, якты образларын бирү (К.Нәҗми. “Хәят апа”, “Сагыну хаты”);

• поэма һәм баллада жанры активлашу (Ф.Кәрим. “Гөлсем”, “Партизан хатыны”, “Тимер һәм тимерче”; К.Нәҗми. “Снайпер Мәрдән”);

• җиңү шатлыгы, киләчәк матурлыгы, интернационализм һәм гуманизм авазлары (Ш.Маннур. Без киләбез күкрәп”; Б.Рәхмәт. “Безне көтәләр”; Ф. Кәрим. “Мин – гуманист”; Х.Туфан. “Гөлләр инде яфрак яралар”).




# Җырым кала
# үткән юлымда...

Бөек Ватан сугышында һәлак булган шагыйрьләребез


Абдулла Алиш


Аитзәк Аитов


Демьян Фәтхи


Әгъзам Камал


Хәбра Рахман


Мөхәммәт Әхмәтгалиев


Нур Баян


Касыйм Вахит


Мифтах Вәдүт


Фатих Кәрим


Муса Җәлил


Гадел Кутуй


Габдулла Галиев


Макс Гатау


Мансур Гаяз



Сөләйман Мөлеков



Исмәгыйль Шәфиев



Хәйретдин Мөҗәй



Әхтәм Әминев



Исхак Закир



Гыйз-эл Габид





Лотфи Вәли



Рәхим Саттар



Абдулла Батталов



# Җиңү тәмен, яшәү ямен,  без белмәсәк, кем белер?..

Бөек Ватан сугышыннан җиңеп

кайткан шагыйрьләребез





9MAYA.ru



Сәхаб Урайский



Әхмәт фәйзи



Шамил Гәрәй



Сибгат Хәким



Мәхмүт Хөсәен



Гали Хуҗи



Самат Шакир



Әхмәт Юныс



Әнвәр Давыдов



Нур Гайсин



Нури Арсланов



Әнәс Галиев



Салих Баттал



Әдип Маликов



Шәйхи Маннур



Зыя Мансур



Шәрәф Мөдәррис



Хисам Камал



Әхмәт Ерикәй



Кави Нәҗми



Нажар Нәҗми



Мостафа Ногман



Зәки Нури



Нәби Дәүли



Сөббух Рафыйков



Бари Рәхмәт



Мөхәммәт Садри



Сирин



Мәхмүд Максуд



Сәйфи Кудаш



Әхмәт Исхак



Мөнир Мазунов



Кави Латыйп



Еллар уза, бөек батырлыкның тере шаһитләре – ветераннар арабыздан бер-бер артлы китә бара. Ләкин дәһшәтле сугыш елларында да тынып тормаган музаларның авазлары - шигырьләр - киләчәк буыннарга шул җиңү юлының Изгелеге һәм Бөеклеге хакында искәртеп торыр.



Аитзәк Аитов

(1908 – 1941)

Шагыйрь Аитзәк Аитов 1908 елның декабрендә хәзерге Саратов өлкәсенең Дергач районы Алтата авылында туа. Кечкенәдән әтисез калып, җиде яшеннән үз көнен үзе күрә башлый — көтү көтә, ялчылыкта йөри. Октябрь революциясеннән соң авылда беренчеләрдән булып комсомолга языла.

1928 елда район комсомол комитеты А.Аитовны Мәскәүгә кыска сроклы курсларга укырга җибәрә. Укып кайтканнан соң, ул туган төбәгендә төрле җаваплы урыннарда эшли, утызынчы еллар башында берникадәр вакыт авыл советы председателе булып та тора.

Илне индустрияләштеру чорында А.Аитов — Донбасста, шахтер хезмәтендә. Шушы елларда ул әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый: шигырьләр, очерклар яза. Алар Донбасста татар шахтерлары өчен чыга торган «Пролетар» газетасында басылалар.

Ватан сугышы башлануга, А.Аитов — фронтның алгы сызыгында. 1941 елның 28 октябрендә, Смоленск өлкәсендәге Демидов шәһәре өчен барган сугышларның берсендә, ул батырларча һәлак була.

А.Аитовның зур булмаган шигъри иҗатында шул чор өчен характерлы темалар — авылны коллективлаштыру, илне саклау, комсомол яшьләр тормышы темалары яктыртыла. Шагыйрь иҗатыннан аерым урнәкләр 1961 елда Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган «Алар сафта» исемле күмәк җыентыкта урын алган.



Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән язучы буларак, А.Аитовның исеме Татарстан Язучылар союзы бинасына куелган мемориаль тактага язылды.



Абдулла Алиш

(1908 – 1944)





Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) 1908 елның 15 сентябрендә элекке Казан губернасының Спас өязе (хәзерге Татарстанның Куйбышев районы) Көек авылында дөньяга килә. Аның бабасы Нурулла шул авылның мулласы булып, әтисе Габделбари абзый, солдат хезмәтендә йөреп кайтканнан соң, ата йортында күбрәк хуҗалык эшләре белән шөгыльләнгән — иген иккән, умарта караган. Ул табигате белән киң күңелле һәм үз заманы өчен алдынгы фикерле кеше буларак, өйгә төрле газета-журналлар алдырган, балаларны кече яшьтән үк хезмәткә өйрәтергә, белемле һәм тәрбияле итәргә тырышкан. Абдулланың әнисе Газизә апа да авыл халкы арасында укымышлы хатын саналган, әдәбиятны бик яратып, шигырь һәм бәетләр чыгарырга һәвәс булган.

Абдулла шушы тату, хөр фикерле һәм хезмәт сөючән гаиләдә кечкенәдән ук зирәк һәм зиһенле малай булып үсә, алты-җиде яшьләрендә әтисеннән укырга-язарга өйрәнә, аннары авылдагы башлангыч мәктәптә укый башлый.

1917 елда тугыз яшьлек Абдулланы әтисе үзләреннән унбиш чакрым ераклыктагы Ямбакты авылы мәдрәсәсенә илтеп бирә. Ул монда 1919 елга кадәр укый. 1919—1921 елларда Бураково авылында яңа ачылган совет мәктәбендә укуын дәвам иттерә, аннары Спас (хәзерге Куйбышев) педагогия техникумы каршындагы җидееллык рус мәктәбен тәмамлый (1927). Мәктәптә уку елларында А. Алиш, фәннәрне бик яхшы үзләштерү белән бергә, драма һәм әдәбият түгәрәкләре, концертлар оештыру, стена газеталары, кульъязма журналлар чыгару кебек эшләрдә башлап йөруче була, үзе дә шигырьләр, хикәяләр яза.

1927 елның җәендә А. Алиш Казанга килә һәм Казан Җир төзү техникумында укый башлый. Техникумда уку чорында (1927—1930) аның әдәбият белән кызыксынуы тагын да үсә: ул әдәбият түгәрәкләренә йөри, техникумда кульъязма рәвешендә чыгып килгән «Кызыл төзүче» исемле газета һәм «Яңа белгеч» журналы редколлегиясенең члены була, техникум һәм яшьләр тормышы турында язган хәбәрләре белән республика көндәлек матбугатында күренә башлый. 1929 елда «Яшь ленинчы» газетасында «Аптул Алишев» имзасы белән аның «Әти, әчмә!» дигән беренче хикәясе басылып чыга. Аннан соң күп тә үтми, пионерлар тормышын, аларның җәмгыятькә файдалы хезмәттә катнашуларын һәм күңелле ял итүләрен тасвирлаган «Бозлар акканда», «Нәни кооператор», «Отряд умартасы» кебек хикәяләре дөнья күрә.

Җир төзү техникумын тәмамлагач, 1930 елның январеннан көзенә кадәр, А.Алиш Минзәлә кантоны җир бүлегендә мелиоратор булып эшли, аннары, 1931—1933 елларда, Казгрэс (ТЭЦ № 1) төзелешендә гидротехника буенча десятник һәм Казан шәһәре канализация төзелешендә техник хезмәтен башкара. 1934 елда яшь белгечне Казанда татарча чыга торган «Техника» журналының җаваплы секретаре итеп билгелиләр. 1937 елдан Беек Ватан сугышы башланганга кадәр А.Алиш «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналы редакциясендә һәм Татарстан радиокомитетында эшли. 1937 елдан башлап, төп эшеннән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогия институтының кичке бүлегендә укый. Бу еллар — язучының иң күп язган, әсәрләре белән үзен киң катлам укучыларына таныткан чор. Аның балалар өчен «Отряд Флагы», «Дулкыннар», «Ант» исемле хикәя жыентыклары, «Иолдыз», «Кечкенә тоткын» исемле пьесалары (беренчесе А. Әхмәт белән бергә язылган) оасылың чыга. Язучы зурлар өчен дә нәтиҗәле эшли: комсомол-яшьләр тормышына багышланган күп санлы очеркларын, «Яңа килен» (1931), «Тиздән туй (1939), «Кыйммәтле җәүһәр» (1940) кебек хикәяләрен, «Күршеләр» 1934; А.Әхмәт белән берлектә) исемле пьесасын яза һәм 1933 елда беренче бишьеллыклар чорындагы Татарстан гиганты — Казгрэс тезелешендә эшләүче кешеләрнең тырыш хезмәтен сурәтләгән «Якты күл буе» исемле повестен бастырып чыгара.

Шулай да А.Алишны балаларның сөекле язучысы дәрәҗәсенә күтәргән җанр — әкиятләр. Әдипнен. «Капкорсак патша» исемле беренче әкияте «Пионер каләме» журналының 1934 елгы 2 нче санында басылып чыга һәм нәни укучылар тарафыннан хуплап каршы алына. Шуннан соңгы елларда (1935— 1940) А. Алиш ике дистәдән артык әкият иҗат итә. Бу әкиятләр балалар психологиясенең бетен нечкәлекләрен тоеп, композицион яктан җыйнак, уку өчен кызыклы итеп, җиңел, музыкаль яңгырашлы, сүрәтләү чараларына бай, образлы тел белән язылган.

Бөек Ватан сугышы башлангач, А.Алиш 1941 елның июль аенда фронтка китә, солдат-радист сыйфатында, Орлов өлкәсендә барган каты сугышларда катнаша. 1941 елның 12 октябрендә Брянск шәһәре янында, Десна елгасы буенда чолганышта калып, фашистлар кулына әсир төшә. 1941 елның кышын Литвадагы хәрби әсирләр лагеренда тотканнан соң, 1942 елның язында фашистлар аны Чехословакиядәге Сандау шәһәренә озаталар. Ахырда ул Польшадагы Седльце шәһәренә, аннан Берлин янындагы Вустраугa килеп эләгә. Монда Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән очраша, алар белән бергә антифашистик оешмада эшли башлый. 1943 елның августында, яшерен оешманың эше ачылып, А. Алиш һәм башка җәлилчеләр кулга алыналар һәм фашист суды тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителәләр. 1944 елның 25 августында 12 сәгать 12 минутта фашист палачлары Абдулла Алишны гильотинада җәзалап үтерәләр.

Ләкин әдипнең гомерен үлем чикләми. Аның гомере әсәрләрендә һәм Ватаны, халкы хакына, аның иреге һәм бәхете хакына күрсәткән шәхси батырлыгында дәвам итә. Абдулла Алиш, көрәштәше Муса Җәлил кебек ук, туган халкы белән бергә киләчәккә горур атлап бара.



Фатих Кәрим
(1909 – 1945)



Фатих Кәрим (Фатих Әхмәтвәли улы Кәримов) 1909 елның 9 гыйнварында элеккеге Уфа губернасының Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстан АССРның Бишбүләк районы) Ает авылында туа. Мәктәпкә кергәнче үк укырга-язарга өйрәнеп, соңыннан беренче баскыч авыл мәктәбенең ике сыйныфын тәмамлый. 1922 елда абыйсы Габдулла Кәримов (шагыйрь Ярлы Кәрим, 1901—1937) аны Бәләбәй шәһәренә алып китә һәм педагогия техникумының хәзерлек группасына укырга урнаштыра. Монда ике ел укып, хәзерлек курсын тәмамлагач (1924), шул ук абыйсы ярдәмендә Казанга килә һәм бер ел Н.К.Крупская исемендәге яшүсмер балалар йортында тәрбияләнә.

1925—1929 елларда Казан Җир төзү техникумында укый. Комсомол сафына керә, җәмәгать эшләрендә актив катнашып, техникумда комсомол оешмасының секретаре, соңыннан профком председателе булып эшли. Ф.Кәримнең әдәби иҗат эше белән җитди шөгыльләнә башлавы да шушы студентлык елларына карый. 1926 елдан республика газеталарында аның көндәлек темаларга, комсомол тормышына кагылышлы мәкаләләре, фельетоннары, соңга таба балалар өчен хикәяләре һәм шигырьләре күренә башлый (Ф.Кәримнең «Хәзер сезнең белән» исемле беренче шигыре «Кечкенә иптәшләр» журналының 1927 елгы 2 нче санында дөнья күрә).

1928 елда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан пионер газетасы «Яшь ленинчы» чыгарыла башлагач, унтугыз яшьлек студент-әдипне газетаның җаваплы секретаре итеп билгелиләр. Анда Ф.Кәрим, техникумдагы укуын дәвам иткән хәлдә, бер ел эшли, аннары, 1929 елда техникумны тәмамлагач, «Крәстиян гәзите» редакциясенә әдәби хезмәткәр булып күчә. 1930—1931 елларда Ф. Кәрим «Азат Хатын», «Атака» (татар пролетар язучылары органы) журналларында жаваплы секретарь хезмәтләрендә була. 1931 елның көзендә армиягә алынып, 1933 елның гыйнварына кадәр Идел буе хәрби округының Казанда татар телендә чыга торган «Кызыларминяче» газетасында хәрби журналисг-хәбәрче булып хезмәт итә. Армиядән кайтканнан соң, Ф.Кәрим Татар дәүләт нәшриятының (Татгосиздатның) яшьләр-балалар әдәбияты секторы җитәкчесе итеп билгеләнә. Үзе өчен зур әдәби мәктәп булган бу җитди, җаваплы эштә Ф.Кәрим 1937 елның май аена кадәр эшли.

1929 елдан 1937 елга кадәрге кыска вакыт эчендә аның ун китабы басылып чыга (икесе — проза, сигезе — шигъри җыентыклар). Утызынчы еллардагы социалистик хезмәт темасын, илнең хуҗалыгын һәм оборонасын ныгыту өчен көрәш темасын яктырткан лирик шигырьләре, «Яшең яктысы» (1932), «Тавышлы таң» (1933), «Илле егет» (1934), «Аучылар» (1934), «Аникин» (1936) кебек поэмалары белән Ф.Кәрим сугышка кадәрге чорда ук заман сулышын яхшы тоеп, ил каршында зур җаваплылык хис итеп яшәүче шагыйрь буларак танылa.

Ф.Кәримнең поэтик таланты аеруча Бөек Ватан сугышы чорында ачыла. Армиягә ул 1941 елның 30 декабрендә алына һәм 1942 елның февраленнән 1945 елның февраленә кадәр алгы сызыкта булып, солдат һәм взвод командиры сыйфатында, Мәскәү яныннан алып Көнчыгыш Пруссиягә хәтле сугышчан юл уза, Украинаны, Белоруссия, Карпатны азат итү сугышларында катлаша, ике тапкыр авыр яралана, шәхси батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Ф. Кәрим сугыш чорында һәр буш минутын иҗат өчен файдалана. 1941—1945 еллар арасында ул тугыз лоэма, ике повесть, бер драма әсәре һәм йөздән артык шигырь яза. Сан ягыннан гына түгел, сыйфат һәм идея-эчтәлек ягыннан да шагыйрьнең бу чор әсәрләре иҗатта яңа биеклеккә күтәрелү, камиллеккә ирешү мисалы булып торалар. Аның поэзиясендә сугыш чынбарлыгының катлаулы фәлсәфәсе, туган ил өчен җаннарын кызганмый көрәшкән совет кешеләренең, совет солдатының табигый эчке кичерешләре, патриотик хисләре, сөйгәненә булган олы мәхәббәте, тыныч тормышка сусавы гаҗәеп бер ихласлык һәм шигърилек белән гәүдәләнә. Ф.Кәримнең бу елларда иҗат иткән лирик шигырьләре, «Гөлсем» (1942), «Идел егете» (1942), «Кыңгыраулы яшел гармун» (1942), «Пионерка Гөлчәчәккә хат» (1942), «Тирән күл» (1942), «Үлем уены» (1942), «Партизан хатыны» (1943), «Өмет йолдызы» (1944) поэмалары, «Тимер һәм тимерче» (1942) балладасы, Муса Җәлилнең Моабит циклы шигырьләре белән бергә, сугыш чоры татар совет поэзиясенең иң югары ноктасын тәшкил итәләр. Бөек Ватан сугышы елларында Ф.Кәрим чәчмә әсәрләр язуга да игътибар бирә: «Шакир Шигаев» (1943) исемле драма, «Разведчик язмалары» (1942) һәм «Язгы төндә» (1944) исемле ике повестен иҗат итә. Бу әсәрләрдә, поэзиясендәге кебек үк, сугыш темасы — батыр совет сугышчыларының җанлы образлары, төрле милләт кешеләреннән оешкан совет армиясенең рухи һәм сугышчан бердәмлеге чагыла.

Гомумән, Ф.Кәримнең иҗат планнары зур була. Ләкин сугыш чынбарлыгының дәһшәтле «үлем уены» аңа үзенең иҗади планнарын ахыргача тормышка ашырырга ирек бирми: 1945 елның 19 февралендә, сугыш бетәргә санаулы гына көннәр калгач, бик җаваплы бер сугышчан заданиене үтәгәндә, кече лейтенант, взвод командиры Ф.Кәрим батырларча һәлак була. Аның гәүдәсе Көнчыгыш Пруссиядәге Кенигсберг (хәзерге Калининград) шәһәре янында күмелә. Соңыннан, 1955 елда, ул шундагы Победа исемле авыл паркына туганнар каберлегенә күчерелә. Сугыштагы соңгы батырлыгы өчен Ф. Кәрим, үлгәннән соң, Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Ф. Кәримнең ялкынлы иҗаты укучылар күңелендә буыннан-буынга яңара бара. 1979—1981 елларда Татарстан китап нәшрияты патриот әдипней өч томлык әсәрләр җыелмасын яңадан бастырып чыгарды.

## Ватаным өчен

Бәлки, бу хат соңгы хатым булыр,
Иж дәһшәтле утка керәмен,
Шулай була калса, кояшны да
Бүген соңгы тапкыр күрәмен.

Мин сугышка керсәм, дошманымның
Йөрәгенә төзәп атамын;
Үзем үлсәм, балаларым кала
Минем гомерем булып, Ватаным.

Кала дөнья, кала бар матурлык,
Ал чәчәкләр кала болында,
Чәчәкләргә төренеп, эзем кала,
Җырым кала үткән юлымда.

Үләм икән, үкенечле түгел
Бу үлемнең миңа килүе,
Бөек җыр ул – Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.



## Теләк

Матурлык сайлауда мине
Кем куып җитәр икән?!
Сөюдә һәм сөелүдә
Мине кем җиңәр икән?!

Яшәдем, яшел урманнар
Иркәләде, көйләде.
Инде мин сугыш кырында,
Тик бер генә теләгем:

Дошманга ялкын сибүче
Җил булып барсам иде,
Тәвәккәллек, батырлыкта
Җыр булып калсам иде.



# Гадел Кутуй

(1903 – 1945)

Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев 1903 елның 28 ноябрендә элекке Саратов губернасының Кузнецк өязе (хәзер Пенза өлкәсенә керә) Татар Кынадысы авылында туа. Башлангыч белемне туган авылы мәктәбендә ала, 1912 елда әтисе Нурмөхәммәт абзый, игенчелек хезмәтен ташлап, гаиләсе белән Самара губернасындагы Алексеевск авылына күчә һәм Кутуевларның күн заводында эшли башлый. Гаделша шунда рус мәктәбендә белем алуын дәвам иттерә. 1917 елда бертуган Кутуевлар (дүрт гаилә) Самара (хәзерге Куйбышев) шәһәренә күчеп киләләр. Булачак язучының белем алуы һәм әдәби сәләтенең ачылып китүе өчен монда шартлар тагын да уңайлаша төшә: мәктәптә уку белән бергә, ул шәһәрдәге эшче клубларының берсендә күренекле рус язучысы Александр Неверов оештырган әдәби түгәрәккә бик актив йөри һәм рус телендә үзенең беренче шигырьләрен яза, нык», лап торып, шул чордагы яңа рус поэзиясе, аерым алганда, В. Маяковский-ның иҗаты белән якыннан таныша.

1920 елда унҗиде яшьлек Кутуй Казанга килә һәм политехника институтының химия факультетына укырга керә. Ләкин ике курсны тәмамлагач институттан китәргә мәҗбүр була һәм Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбендә әдәбият укытучысы булып эшли башлый. Шушы чорда аның әдәби иҗат эшчәнлеге дә активлашып китә. 1923 елгы «Безнең юл» журналының дүртенче, бишенче саннарында «Яшь футурист шагыйрь» дигән баш белән Г. Кутуйның бер бәйләм шигырьләре басылып чыга. 1924 елда исә «Көннәр йөгергәндә» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә. Нигездә рус футуристларына һәм В. Маяковский шигырьләренең тышкы формасына ияреп язылган, аерым уңышлы чагыштырулар, образлы тәгъбирләре булса да, тулаем аңлаешсыз яңгыраган бу шигырьләр ул заманның әдәби хәрәкәтендә зур шау-шу кузгаталар һәм, поэзиянең үткәндәге уңай традицияләре» инкяр итү үрнәкләре буларак, каты тәнкыйтькә очрыйлар. Тора-бара иҗатында бу кимчелекләрне Г. Кутуй үзе дә таный һәм, формалистик мавыгулардан арына барып, егерменче елларның икенче яртысында иҗат иткән шигъри әсәрләрендә яңалыкны яклау идеясен язу стилендәге «шаккатризмнар» белән түгел, ә мәгънәгә кулай реалистик сурәтләү чаралары ярдәмендә бирергә омтыла башлый.



1925 елда Г. Кутуй Казан Көнчыгыш педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1929 елда институтны уңышлы тәмамлап чыккач, утызынчы еллар дәвамында Казан коммуналь төзелеш инженерлары институтында гыйльми секретарь, мәктәпләрдә һәм Казан авиация техникумында әдәбият укытучысы булып эшли.

Г. Кутуйның бу еллардагы әдәби иҗат эшчәнлеге гаҗәп күп кырлы. Ул шигырьләр, хикәяләр, пьесалар яза, «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан»), «Красная Татария» (хәзерге «Советская Татария») газеталарында, «Безнең юл», «Яңалиф», «Авыл яшьләре», «Чаян» журналларында күп санлы фельетон, очерк, мәкаләләр бастыра, Татар академия еатрының һәр яңа спектакленә диярлек рецензияләр язып бара. Үз чорының төрле әхлакый проблемаларына багышланган «Балдызкай» (1926), «Күк күгәрчен» (1929), «Җавап» (1929) һәм «Казан» (1927) исемле пьесалары Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала. Әдип үз әсәрләрендә яңа кеше формалашу, бигрәк тә интеллигенция вәкилләренең тормыштагы урыны һәм роле мәсьәләләрен күтәреп чыга, совет кешеләренең рухи байлыгын, хезмәт шатлыгын чагылдыра. «Солтанның бер көне» (1938) повесте, «Вөҗдан газабы» (1939), «Нишләргә?» (1940), «Илһам» (1941), «Рәссам» (1941) кебек хикәяләре, «Талантлар Вабаны» (1937) поэмасы әнә шундыйлардан.

1935 елда Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте басылып чыга («Совет әдәбияты», 1935 ел, № 9—12 саннар). Гади бер татар кызының тормыштагы авырлыкларны җиңә-җиңә җәмгыятьтә үз урынын табуын, хезмәт һәм гаилә бәхетенә ирешүен гаҗәеп самими рәвештә, публицистик күтәренкелек белән сурәтләгән бу кечкенә генә повесть күп буын укучыларының яратып укый торган китапларыннан берсенә әверелә. Татар телендә генә дә ул унлап басмада чыга. Рус телендәге басмалары ике дистәдән, артып китә. Рус теле аша повесть СССР һәм дөнья халыклары телләренә (инглиз, француз, гарәп, корея, албан, монгол, вьетнам, чех, казакъ, үзбәк, кыргыз, чуваш, мари һ. б.) тәрҗемә ителә.

Бөек Ватан сугышы башлану белән Г. Кутуй үзенең язучылык сәләтен дошманны җиңү өчен көрәшкә багышлый: патриотик шигырьләр, публицистик мәкаләләр, хикәяләр яза. 1942 елның июнендә ул үзе дә фронтка китә, Сталинградны саклаучы Дон фронтының авыр гвардия миномет бригадасы политбүлегендә хезмәт итә. Идел буендагы мәгълүм тарихи җиңүгә турыдан-туры катнашкан өчен аны «Батырлык өчен» һәм «Сталинградны саклау өчен» медальләре белән бүләклиләр. Сталинградтан соң Г. Кутуй үзе хезмәт иткән гвардия бригадасы составында Волхов, Брянск, Великие Луки шәһәрләрен азат итүдә катнаша. Авыр һәм мәшәкатьле солдат хезмәтен башкару белән бергә, ул иҗат эшен дә дәвам иттерә: фронт газеталарында хәбәрләр, мәкаләләр бастыра, әдәби монтажлар төзи, 1944 елда, Казанга вакытлыча иҗади ялга кайткач, балалар өчен «Рөстәм маҗаралары» исемле мәгълүм повестен («хыялый роман») яза. 1944 елның көзендә Г. Кутуй Беренче Белоруссия фронтында чыга торган «Кызыл Армия» газетасы редакциясенә күчерелә. Монда әдипнең күп кенә очерклары, корреспонденииияләре, «Без — сталинградчылар» исемле нәсере һәм «Хәнҗәр» дигән хикәясе басыла. Шушы ук чорда әдипнең ил азатлыгы өчен көрәшүче совет солдатының изге хисләрен сәнгатьчә югарылыкта яңгыраткан атаклы «Сагыну» нәсере иҗат ителә.

1945 елның язында Г. Кутуй, сәламәтлеге бик начарланып, хәрби госпитальгә эләгә һәм, шул авыруыннан терелә алмыйча, 1945 елның 15 июнендә Польшадагы Згеш шәһәрендә вафат була. Аның мәрмәр таш куелган каберен Польша пионерлары кадерләп саклыйлар һәм яз саен аңа чәчәкләр утырталар.



Абдулла
Батталов
(1916 – 1944)

Абдулла Вазих улы Батталов 1916 елның 1 маенда Татарстанның Биләр (хәзерге Алексеевский) районы Олы Тигәнәле авылында туа.
Авыл мәктәбендә җиде класс бетергәннән соң, колхозда эшли. Чистайда, Донбасста эшләп ала. 1937 елны аны армиягә алалар. Абдулла бик теләп бара, чөнки кече чшьтән үк хәрби кеше булырга хыяллана. Ул Казанда, Кремльдә хезмәт итә. Аны кече командирлар курсына укырга билгелиләр. Ләкин көтмәгәндә Абдулла бәхетсезлеккә очрый: аягын имгәтә. Госпитальдә ятып чыкканнан соң, хәрби хезмәткә яраксыз дип, аны өенә кайтарып җибәрәләр.

Олы Тигәнәледә Абдулланы клуб мөдире итеп куялар. Һәрбер чарада конферансье да, артист ат, укучы-декламатор булып та катнаша. Әдәбият белән мавыга, күп укый, аеруча Такташ поэзиясен ярата. Үзе дә шигырь язгалый. Кайбер язмаларын район газетасына җибәреп карый. Аның әсәрләрен яратып кабул итәләр, газета битләрендә бастыралар. Бераздан үзен дә редакциягә чакырып, корреспондент урыны тәкъдим итәләр. Сугыш алдыннан Абдулла берничә ай редакция хезмәткәре булып эшли.



Бөек Ватан сугышы башлану белән, аягы зәгыйфь булуга карамастан, Абдулла фрнтка омтыла һәм үз теләгенә ирешә. Аның кайда ничек сугышканы, ничек әсирлеккә төшүе әлегә билгеле түгел.



Демблин лагеренда Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән очраша. Алар белән бергә антифашистик оешмада эшли башлый: элемтәче вазифасын үти. 1943 елның августында, яшерен оешманың эше ачылганнан соң, җәлилчеләр кулга алыналар һәм фашист суды тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителәләр. 1944 елның 25 августында 12 сәгать 27 минутта фашист палачлары Абдулла Батталны гильотинада җәзалап үтерәләр.



Исмәгыйль Шәфиев

(1913 – 1943)



Шәфиев Исмәгыйль Шәфи улы 1913 елда Башкортстан АССР Кыйгы районы Югары Кыйгы авылында туа. 1929 елны үз авылларында җидееллык мәктәпне тәмамлый һәм педрабфакка керә. 1933 елны аны тәмамлый, 1935 елга кадәр күп тиражлы МТС газетасында һәм “Социализмга” исемле шул район газетасы редакторы урынбасары булып эшли. Яшьтән үк шигырьләр яза.

1935 – 1937 елларда Ерак Көнчыгышта кече артиллерия командиры булып хезмәт итә.

Армиядән кайткач, Казан укытучылар институтында укый. Татарстан АССР Ворошилов районы Олы Нөркәй урта мәктәбенә укытучы итеп җибәрелә. Ул анда да читтән торып укуын дәвам иттерә. 1941 елның июнендә фронтка китә.

Лейтенант-танкист И.Шәфиев Калинин фронтында чыга торган татар фронт газетасында һәм “Совет әдәбияты” журналында үзенең шигырьләре белән актив катнаша. И.Шәфиев 1943 елның 17 сентябрендә Смоленск өлкәсенең Кузьмиченко авылы янында батырлар үлеме белән һәлак була.



## Демьян Фәтхи

(1906 – 1943)

Демьян Фәтхи (Фәтхетдинов Касыйм) 1906 нчы елны Самара губернасы Татар Колмаеры (хәзерге Ульян өлкәсе Чардаклы районы) авылында туа.

1921 нче елны Самарада Татар-башкорт педагогия техникумына укырга керә һәм шушы елны ук шигырьләр яза башлый.

1926 нчы елны ул Казанда татрабфакта укый. Бу елларда ул “Кызыл Татарстан” һәм “Советлар канаты” газеталары редакцияләрендә эшли.

Демьян Фәтхинең беренче шигырьләр җыентыгы 1929 нчы елны “Тальян” исеме белән Татгосиздатта басылып чыга. 1931 нче елны “Металл тавышлары” исемендәге икенче шигырьләр җыентыгы Мәскәүдәге “Центриздат” тарафыннан басыла.

Болардан башка аның “Бүреләр”, “Бояр урманында” исемле җыентыклары, күп кенә тәрҗемә хезмәтләре дә бар. Ул “Минем нәселем” исемле роман өстендә дә эшли.

Демьян Фәтхи үзенең шигырьләре, хикәяләре белән “Безнең юл”, “Яңалиф”, “Совет әдәбияты” журналлары һәм төрле газеталарда актив катнашып килә. 1935 нче елны үзе теләп Ерак Көнчыгышка китә. Анда сигез еллап төрле предприятиеләрдә төрле эштә эшли, Себер һәм Ерак Көнчыгыш турында күп кенә шигырьләр иҗат итә. Аннан кайту белән Яшел Үзән заводларының берсендә гади эшче булып эшли.

Демьян Фәтхи Бөек Ватан сугышы башлану белән илебезнең азатлыгын сакларга китә. Бөек Сталинград сугышларында катнаша, өч тапкыр яралана. Тормышны тирән сөюче, үткен фикерле, шат күңелле, талантлы шагыйрь Д.Фәтхинең иҗат юлы вакытсыз өзелә: ул 1943 нче елны Кантемерово янында барган каты сугышларда батырлар үлеме белән һәлак була.





Сөләйман Мөлеков

(1920 – 1941)



Сөләйман Мөлеков 1919 елның 5 гыйнварында Пыжмара авылында туган. Авыл мәктәбендә укыган һәм җәйләрен колхоз кырларында җиң сызганып эшләп йөргән елларда тормышның гүзәллеге, туган авылының табигате яшь егетнең күңел кылларын тибрәтә. Беренче шигырьләрен ул менә шул вакытта яза.

Шода авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Алабуга китапханә техникумы каршындагы китапханәчеләр хәзерләү курсына укырга керә. Курсны бик яхшы билгеләренә генә бетереп, Түнтәр авылында китапханә мөдире, Субаш авылында укытучы булып эшли. Шушы чорда шигырьләре өлкә газеталарында, альманахларда, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналында басыла.

1940 елда Кызыл Армия сафларына алына һәм Көнбатыш Украинада чик сакчысы булып хезмәт итә. Бөек Ватан сугышының беренче көненнән үк фашистларга каршы сугышка керә. 1941 елның сентябрендә Киевны дошманга бирмәс өчен барган аяусыз сугышларның берсендә һәлак була. Ул үтә яшь килеш шәһит булып якты дөньядан китә. Ләкин аның әле үсмерләрчә беркатлы, эчкерсез, самими шигырьләре үлемсез, алар безнең белән. Якташлары аны онытмый. Пыжмара авылының үзәк урамы Сөләйман Мөлеков исемен йөртә, мәктәп музеенда аңа багышланган стенд бар.

Казанның Матбугат йортында Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучылар истәлегенә куелган мемориаль такта бар — анда алтын хәрефләр белән Сөләйман Мөлеков исеме дә язылган.



# Рәхим Саттар

(1912 – 1943)

Рәхим Саттар (Габделрәхим Сөләйман улы Габделсаттаров 1912нче елның 15 августында хәзерге Башкортстанның Чишмә районы Түбән Хаҗәт авылында туа. 1943 елның июнендә хәбәрсез югала.

Әсирлектән качкан журналист һәм шагыйрь Рәхим Саттар җир йөзендә нибары 31 яшь кенә яшәп кала. Аның язмышы хәзергәчә тулаем мәгълүм түгел. Ә блокноты, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» кебек үк, Татарстанның Милли музеенда саклана.





Хәйретдин Мөҗәй

(1901 – 1944)

Шагыйрь һәм прозаик, Бөек Ватан сугышы каһарманы Хәйретдин Мөҗәй (Мөҗәһит Хәйретдин улы Хәйретдинов) 1901 елның 26 мартында Башкортстан республикасының Туймазы районы Төрекман авылында туа. 18 яшендә Х.Мөҗәйне Кызыл Армиягә алалар һәм шул вакыттан соң аның бөтен гомере хәрби хезмәткә бәйле рәвештә уза. Ул озак еллар чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә, Урта Азиядә басмачыларга, кулак бандаларына каршы көрәшә, 1938 елда Хасан күле янында япон самурайларына каршы барган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Бер үк вакытта Х. Мөҗәй әдәби иҗат эше белән шөгыльләнергә дә вакыт таба: 20нче еллар ахырыннан башлап газета-журнал битләрендә аның хәрби тормышка, чик саклаучыларның көндәлек хезмәтенә багышланган һәм аларның уй-фикерләрен чагылдырган шигырьләре, очерк, хикәяләре еш басыла. 1932 елда аның Казанда “Мылтыклар” дигән беренче китабы чыга.

Х.Мөҗәй Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк алгы сызыкка баса, полк командиры булып дәһшәтле бәрелешләрдә катнаша, кыюлык һәм шәхси батырлык үрнәкләре күрсәтә. Ләкин 1942 елның җәендә, Харьковка һөҗүм вакытында, Х.Мөҗәй командалык иткән полк дошман чолганышында кала һәм, айдан артыкка сузылган авыр бәрелешләрдән соң, исән калган авыр яралылар, шул җөмләдән подполковник Х.Мөҗәй, фашистлар кулына эләгә.



Х.Мөҗәйне, башка совет әсирләре белән бергә, Германиягә озаталар. Ул әсирлектә дә фашизмга каршы көрәшен туктатмый: Мюнхен шәһәрендәге совет хәрби әсирләре лагеренда төзелгән антифашистик яшерен оешма җитәкчеләренең берсе була. Ләкин 1943 елның ахырында гестапо яшерен оешманың эзенә төшә, җитәкчеләрен Дахау концлагерена яба һәм, озак газапланулардан соң үлемгә хөкем итә. 1944 елның 4 сентябрендә фашист палачлары атып үтергән туксан ике Дахау тоткыны арасында



Әхтәм Әминев

(1918 – 1942)



Әхтәм Әмин улы Әминев 1918 елда хәзерге Башкортстан АССРның Миякә районы Әнәч авылында крестьян гаиләсендә туа. 1933 елда җидееллык авыл мәктәбен тәмамлагач, Свердловск педагогия техникумына укырга керә. Техникумда укыган елларында беренче шигырьләрен яза һәм Свердловскида чыга торган газеталарда бастыра.

1937 елны Ә. Әминев укуын дәвам итәр өчен Казанга килә һәм 1941 елда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле, әдәбияты бүлеген тәмамлый. Яшь авторның бу чордагы шигырьләре «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре»), «Яшь ленинчы» газеталарында, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналы битләрендә һәм «Очкыннар», «Туган ил» кебек күмәк җыентыкларда дөнья күрә.

Таланты ачылып килгән яшь шагыйрь 1941 елның декабрендә фронтка китә. 1942 елның апрелендә Калуга өлкәсенең Сухиничи, Мещовск шәһәрләре янында барган сугышларда каты яраланып, шул ярадан вафат була. Ә. Әминев шигъри иҗатыннан аерым үрнәкләр Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Алар сафта» (1961) исемле күмәк җыентыкка кертелгән.

Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән солдат-шагыйрь буларак, Ә. Әминевнең исеме Татарстан Язучылар союзы бинасына куелган мемориаль тактага язылды.



Хәбра Рахман
(1914 – 1942)

Хәбра Рахман (Хәбибрахман Габдрахман улы Габдрахманов) 1914 елда хәзерге Татарстанның Балтач районы Яңгул авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Сигез яшендә чагында әти-әнисез калып, ятчш балалар йортында тәрбияләнә. 1930 елда Арча мәктәбенең җиде классын тәмамлап, авылда укытучы булып эшли башлый. Шушы елларда «Ялчы» дигән крестьян газетасында аның беренче шигырь һәм хикәяләре басыла.

1931—1936 елларда Хәбра Рахман Казанда Татрабфак-та, аннары дәүләт педагогия институтында белем ала. Институтны отличнога тәмамлаганнан соң, аны татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп Алабуга педагогия училищесына эшләргә җибәрәләр. 1938—1940 елларда Хәбра Рахман гаскәри хезмәттә була, Халхин-Голдагы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, яралана, шәхси каһарманлыгы өчен «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.

Армиядән кайткач, Хәбра Рахман Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр башта Алабуга педагогия училищесында һәм китапханә техникумында тел-әдәбият укытучысы, аннары Алабуга район газетасының редакторы булып эшли. Сугыш башлануга, ул фронтка китә һәм, Мәскәү янындагы каты сугышларның берсендә авыр яраланып, шул ярадан савыга алмыйча, 1942 елның ноябрендә вафат була. Аның гәүдәсе Калинин өлкәсенең Максатиха дигән тимер юл станциясендә күмелә.

Хәбра Рахманның әдәби мирасы зур түгел. Көндәлек матбугатта басылган шигырьләрен дә үз эченә алып, 1937 елда аның «Чәчәк ява» исемле бердәнбер мөстәкыйль җыентыгы дөнья күрә (Казан, Татгосиздат, 47 б.). Моннан башка газета-журналларда кечкенә-кечкенә хикәяләре һәм Халхин-Гол вакыйгаларына багышланган «Сугышта» («Совет әдәбияты», 1940) исемле зур гына очеркы басылып чыга. Сугыш алдыннан ул шулай ук «Шомырт чәчәкләре» исемле повесть өстендә эшли, ләкин әсәр тәмамланмый кала. Хәбра Рахман әсәрләренең, бигрәк тә шигъри иҗатының төп эчтәлеген күмәкл чорын кичергән яңа авыл тормышы һәм мәхәббәт лирикасы били.



Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән язучы-солдат буларак, Хәбра Рахманның исеме Татарстан Язучылар союзы бинасына куелган мемор тактага язылды.



Мөхәммәт Әхмәтгалиев

(1920 – 1943)



Шагыйрь Мөхәммәт Ибраһим улы Әхмәтгалиев 1920 елның 21 февралендә Казан шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. 1938 елда Яңа Бистәдәге 13 номерлы татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1938—1941 елларда Казан дәүләт педагогия институтының биология факультетында белем ала.

Ватан сугышы башлангач Казанда производствода станочник булып эшли. 1942 елның 22 маенда фронтка китә һәм 1943 елның 27 августында Смоленск шәһәре тирәсендә барган каты сугышлар вакытында һәлак була.

М.Әхмәтгалиев 1934 елда яза башлый. Беренче шигырьләре 1935 елда «Мехчы», «Яшь ленинчы» газеталарында, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналы битләрендә дөнья күрә, соңга таба «Шат балалык», «Алмаш», «Очкыннар», «Беренче көн» кебек күмәк җыентыкларда һәм альманахларда басыла.

1941 елда яшь шагыйрь үзенең шигырьләре тупланган беренче җыентыгын басмага әзерли, әмма сугыш башлану сәбәпле ул җыентык матбугатка чыкмый кала. 1957—1960 еллар арасында М.Әхмәтгалиевнең «Балык тотканда», «Тегүче куян», «Елак батыр» исемле кечкенә күләмле өч китабы басылып чыкты.

М.Әхмәтгалиев шигырьләре эчтәлек ягыннан бәхетле балачак, комсомол, илне саклау кебек шул чор поэзиясе өчен характерлы темаларга багышланган. Аның шагыйрлек сәләте бигрәк тә кече һәм урта яштәге балалар өчен язган шигырләрендә ачык күренә. Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән солдат-шагыйр буларак, М.Әхмәтгалиевнең исеме Татарстан язучылар союзы бинасына куелган мемориаль тактага язылды.



Исхак Закиров
(1911—1944)

Исхак Кадыйр улы Закиров 1911 елның 14 сентябрендә Казан шәһәрендә туа. М.Вахитов исемендәге татар урта мәктәбендә җиде класс белем алганнан соң, хисапчылар курсын, аннары, читтән торып укып, Казан «финанс-экономика институтын тәмамлый. 1934—1941 елларда башта Татарстан дәүләт нәшриятында, соңыннан Татарстан язучылар союзында хисапчы һәм бухгалтер булып эшли. Бөек Ватан сугышы башлану белән, Исхак Закиров фронтка китә, сугышларда катнаша, дошманны куа-куа, совет гаскәрләре белән бергә Белоруссия җирләренә кадәр барып җитә. Фронтта ул партия сафына алына, сугышчан «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. 1944 елның 14 июлендә Витебск өлкәсенең Городилово авылы тирәсендә барган каты сугышта парторг Исхак Закиров, ротаны һөҗүмгә күтәреп, дошман ныгытмаларын атакалаганда каһарманнарча һәлак була. Шушы һөҗүм вакытындагы шәхси батырлыгы өчен ул Совет хөкүмәте тарафыннан Икенче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Исхак Закировның шигырьләре көндәлек матбугатта 1929 елдан басыла башлый. Шагыйрьнең иҗат мирасы артык зур түгел, ләкин шул кечкенә мирасta да аның поэтик фикер йөртә белүе, тормыш күренешләрен, кеше йөрәгендәге хис-тойгыларны шигъри тел белән әйтеп бирергә омтылуы ачык күренә. Шигырьләренең күпчелеге патриотизм, интернационализм, батырлык  темаларына багышланган. Бу темалар шагыйрьнең Бөек Ватан сугышы чорында иҗат иткән шигырь һәм очеркларында аеруча калку төс ала. Сугыш елларында аның очерклары һәм шигырьләре «Алга, дошман өстенә!» дигән фронт газетасында һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында басылалар.



Исхак Закиров шигъри иҗатының аерым үрнәкләре «Татар поэзиясе ан тологиясе» (1956), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта (1961) һәм «Утлы еллар поэзиясе» (1972) исемле җыентыкларга кертелгән Ватан азатлыгы чөчен гомерен биргән язучы-солдат буларак, Исхак Закировның исеме Татарстан Язучылар союзы бинасына куелган мемориаль тактага язылды



Нур Баян
(1905 – 1945)



Нур Баян (Нур Галим улы Баянов) 1905 елның 5 маенда Татарстанның хәзерге Актаныш районы Әнәк авылында туа.1921 елгы ачлык аны туган авылыннан китәргә мәжбүр итә. Ул Пермь шәһәренә барып, кара эшче булып эшли, ә 1923 елда, укуын Казанга килә һәм Татар-башкорт хәрби мәктәбенә курсант итеп алына. Шушында укыганда аның әдәби иҗат эше башлана: авыл, гражданнар сугышы, илне саклау турында беренче шигырьләрен яза, һәм 1925 елдан аның исеме матбугатта инде бик еш күренә башлый. 1928 елда ул «Кызылармеец» дигән хәрби газета редакциясенә әдәби хезмәткәр булып урнаша һәм шул ук елда «Уракчы кызлар», «Ќимерелгән окоплар» исемле ике шигъри җыентыгын бастыра.

1929—1930 елларда Н. Баян «Колхоз яшьләре» журналының секретаре булып эшли, аннан Чаллы район газетасы редакторы итеп билгеләнә. Газетада, районда эшләү дәверендә «Клеверлы кырлар» (1929), «Яңгырлы төн» (1933) кебек поэмаларын һәм күп санлы шигъри әсәрләрен иҗат итә.

1932 елда 1932—1938 елларда Татарстан Язучылар союзы оештыру комитетында инструктор, Татгосиздатта редактор, аннары матур әдәбият бүлегенең өлкән редакторы булып эшли. 1938 елдан Беек Ватан сугышы башланганчыга хәтле ул зур күләмле «Гөләндәм» (1939), «Ќимерелгән дворец янында» (1940), Г. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»ына ияреп «Карахмәт» (1940) поэмаларын яза, «Язгы төн», «Туган авыл», «Шат җырлар» исемле шигырь җыентыкларын бастырып чыгара. Әдәби иҗат эшчәнлегендәге уңышлары өчен һәм Совет Татарстаны төзелүенең егерме еллыгы уңае белән Совет хекүмәте аны 1940 елда «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкли.

Н. Баян Беек Ватан сугышының беренче көннәреннән ук фронтка китә һәм ахырга кадәр диярлек башта полк партия оешмасы секретаре, аннары дивизия газетасы редакторы һәм, ниһаять, полк командирының политик эшләр буенча урынбасары сыйфатында алгы сызыкта була. Фронттагы батырлыклары өчен ул Беренче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә. Авыр сугыш шартларында да иҗат итүдән туктамый, патриотик шигырьләр яза, поэма һәм либретто өстендә эшләвен дәвам итә. Ләкин Ќиңү көненә нибары унбиш көн кала, 1945 елның 23 апрелендә, Австрияне азат итү өчен барган сонгы сугышларның берсендә Совет Армиясе подполковнигы, шагыйрь Нур Баян батырларча һәлак була.



Касыйм Вахитов

(1916 – 1942)

Касыйм Вахит (Касыйм Мисбах улы Вахитов) 1916 елның 16 мартында хәзерге Башкортстанның Әлшәй (Раевский) районы Нигъмәтулла авылында туа. 1935 елда, Дәүләкән педагогия техникумын тәмамлап, шул ук районның Искәндәр авылындагы тулы булмаган урта мәктәптә (ТБУМда) физика-математика укытучысы булып эшли башлый. 1937 елда Казанга килә һәм педагогия институтына укырга керә.

Касыйм Вахитның беренче шигырьләре 1932—1933 елларда Уфадагы «Коммуна» исемле өлкә газетасында басыла башлый. Соңрак ул Татарстан өлкә матбугатында — «Кызыл Татарстан» газетасы, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары»), «Чаян», «Азат хатын» журналларында актив языша. Аның шигырь цикллары шулай ук «Дуслык», «Очкыннар», «Бәхетле яшьләр» исемле күмәк ќыентыкларга кертелә. Яшь шагыйрь, өйрәнү чоры кичереп, шигъри форманы төрләндерү юнәлешендә тәҗрибәләр ясый, поэзиянең терле жанрларында көчен сынап карый. Аның зур булмаган әдәби мирасында «Сөйләнмәгән экият» исемле поэма да, Көнбатыш Украинаны азат итүгә багышланган «Егет турында баллада» да, юмористик шигырьләр, сюжетлы шигырьләр һәм кечкенә лирик парчалар да бар.

Бөек Ватан сугышы башлануга, әле яңа гына институтны тәмамлаган Касыйм Вахит узе теләп фронтка китә һәм сугышның беренче айларыннан ук алгы сызыкта сугыша, шәхси батырлыклары өчен медальләр белән бүләкләнә. Касыйм Вахит 1942 елның 4 октябрендә Сталинград өлкәсендә барган каты сугышларның берсендә батырларча һәлак була. Сугышчан иптәшләре аны зур хөрмәт белән Шелемка дигән авыл янындагы туганнар каберлегенә күмәләр.



Касыйм Вахит поэзиясенең аерым үрнәкләре сугыштан соңгы чорда «Татар поэзиясе антологиясе»ндә (1956), «Җыр һаман яңгырый» (1956), «Алар сафта» (1961) һәм «Утлы еллар поэзиясе» (1972) исемлеҗыентыкларда басылып чыкты.

Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән язучы-солдат буларак, Касыйм Вахитның исеме Татарстан Язучылар союзы бинасына куелган мемориаль тактага язылды.



Мифтах Вәдүт

(1915 - 1942)

М. Вәдүт (Вәдүт Кәшшаф улы Мифтахов) 1915 елның 20 ноябрендә хәзерге Татарстан АССРның Сарман районы Яхшы Каран авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Сарманда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, 1931—1934 елларда Лубян урманчылык техникумында, аннан Казан дәүләт педагогия институтында укый. 1939 ел да институтта югары белем алып чыккач, Бөек Ватан сугышына хәтле Татарстанның Питрәч районы Шәле авылы урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта.

Бөек Ватан сугышы башлануга, М.Вәдүт фронтка китә. Мәскәү тирәсендәге канкойгыч сугышларда катнаша, шәхси батырлыкар күрсәтеп, гади солдаттан полк комсоргы-политругы дәрәҗәсенә күтәрелә. Шушы авыр сугыш шартларында ул Коммунистлар партиясенә членлыкка кандидат итеп алына. Ләкин М.Вәдүткә Җиңү көнен күрергә язмый: Тула өлкәсендәге каты сугышлар вакытында, 1942 елның 30 мартында фашистлар һөҗүмен кире кайтарганда ул батырларча һәлак була. Сугышчан иптәшләре М. Вәдүтнең гәүдәсен зур хөрмәт белән Тула өлкәсенең Рыдань авылындагы туганнар каберлегенә җирлиләр.

М. Вәдүтнең әдәби мирасы зур тугел. Аның исеме матбугатта утызынчы еллар уртасында күренә башлый. 1939 елда «Шигырьләр» исеме белән беренче җыентыгы басылып чыга, аннан соң балалар љчен язган күләмле поэмасы — «Ятим малай турында әкият»е (1939—1940) дљнья күрә. Шигырьләрендә М. Вәдүт канатлы яшьлек, дуслык-мәхәббәт, азат хезмәт шатлыгы турында илџамланып сљйли. «Ятим малай турында әкият»тә исә яшь шагыйрьнең халык иҗатын ныклап љйрәнүе, халыкның җанлы сљйләү телен шигырь тукымасында оста файдалануы ачык күренә.



М. Вәдүт фронтта чакта да иҗат эшен туктатмый. Аның сугыш чоры иҗатыннан кайбер үрнәкләр «Җыр һаман яңгырый» (Казан, 1956) џәм «Алар сафта» (Казан, 1961) исемле күмәк җыентыкларда урын алган.



Мифтах Вәдүт



***

*Шундый ямьле тормыш итә идек,*
*Шундый татлы иде көннәрем.*
*Егерме биш елдан артык яшәп,*
*Мондый матур тормыш күрмәдем.*
*Тылсымлы бер төш күк үтеп китте,*
*Кыска булды кавышу чорыбыз.*
*Тик кайгырма, бәгърем,*
*Бу көчле җыр*
*Дәвам итәр аерым булсак та;*
*Бергә кушылыр йөрәк авазыбыз,*
*Теләгебез яңрар бер сафта.*
*Һәрбер секунд сине сагынып үтәр,*
*Матур уйлар белән яшәрмен,*
*“Саумы, иркәм!” диеп, аяз төндә*
*Йолдызларга карап дәшәрмен.*
*Син йокыңнан торып, аяз төндә*
*Тәрәзәдән күккә карарсың.*
*Ышан, бәгърем, әгәр исән булсам,*
*Күз нурыңны шуннан табарсың.*

*1941.*



## Гиз-эл Габид
(1917-1943)

Фронтовик шагыйрь Гиз-эл Габид (Гыйздулла Лотфи улы Габидуллин) 1918 елның 7 гыйнварында Оренбург өлкәсенең Тоцкий районы Хөсәен (Саиновка) авылында туа. Җидееллык авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1935—1937 елларда Богырыслан педагогия техникумында укый. 1938 елда Кызыл Армиягә алынып, Көнчыгыш Себердә хезмәт итә. Ватан сугышында катнаша, гади солдат, соңыннан фронт газетасы хәбәрчесе — офицер сыйфатында Ленинградтан алып Финляндия һәм Төньяк Норвегиягә кадәр сугышчан юл уза, фашистлар Германиясе җиңелгәч, яңадан Ерак Көнчыгышка китеп, япон империалистларына каршы сугыша, совет гаскәрләре белән бергә Маньчжурия һәм Төньяк Корея җирләренә кадәр барып җитә.

1946 елда армиядән демобилизацияләнгәч, Гиз-эл Габид Урта Азиядә яши, Үзбәкстандагы Карши һәм Шәһресабз шәһәрләрендә балалар укыта. Ватан сугышында алган яралардан сәламәтлеге какшаган Гиз-эл Габид 1955 елда утыз җиде яшендә вафат була.

Гиз-эл Габиднең зур булмаган әдәби мирасы (иллеләп шигырь) Ватан сугышы чоры солдат поэзиясенең бер сәхифәсе буларак игътибарга лаек. Аның шигырьләре окопта, сугыш тынып торган ял вакытларында, Төньякның кырыс таш-таулары арасында иҗат ителә. Аларда сугыш чынбарлыгы, шагыйрь үзе кичергән, үзе күргән вакыйгалар сурәтләнә, совет солдатының җиңүгә булган ышанычы, оптимистик хисләре, дошманга чиксез нәфрәте поэтик чагылыш таба.

Гиз-эл Габид иҗатыннан аерым үрнәкләр (утыздан артык шигырь) «Алар сафта» (1961) һәм «Беренче карлыгачлар» (1968) исемле күмәк җыентыкларда басылып чыкты.





Макс Гатау
(1913 – 1941)

Шагыйрь Макс Гатау (Гайнетдин Зәйнетдин улы Гатауллин) 1913 елда хәзерге Курган өлкәсенең Әлмән районы Тозау авылында туа. Яшьтән ятим калып, балалар йортында тәрбияләнә, шунда җиде класс белем ала, аннары Чиләбе өлкәсенә китеп, авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый. 1937 елда ул Казан дәүләт педагогия институтының читтән торып уку бүлегенә кабул ителә.

М.Гатау бала чактан ук әдәбият белән кызыксына, халык авыз иҗатын өйрәнә, җырлар, бәетләр җыя. Урал табигате, андагы социалистик төзелеш күренешләре, күмәк хезмәт тантанасы — яшь шагыйрьнең 1939 елда басылып чыккан «Урал мәхәббәте» исемле беренче шигъри җыентыгының төп эчтәлеген шул тәшкил итә.

М.Гатау икенче җыентыгын да басмага әзерли, ләкин Ватан сугышы башлану сәбәпле китап чыкмый кала. М.Гатау 1941 елның июлендә фронтка китә һәм шул елның 20 ноябрендә Калинин өлкәсендәге Гаврилово авылы янында барган каты сугышларның берсендә батырларча һәлак була.

М. Гатауның зур булмаган әдәби мирасыннан аерым үрнәкләр 1961 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Алар сафта» исемле җыентыкта урын алган.



Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән солдат-шагыйрь буларак, М. Гатау-яың исеме Татарстан Язучылар союзы бинасына куелган мемориаль тактага язылды.



Габдулла
Галиев
(1920 – 1941)



Габдулла Гали улы Галиев 1920 елның 20 июнендә Татарстан АССРның хәзерге Саба районы Шәдке авылында укытучы-мөгаллим гаиләсендә туа. 1935 елда Шәдке җидееллык мәктәбен тәмамлагач, Казанга килеп, педагогия институты каршындагы рабфакка укырга керә. Шушы чорда аның әдәби иҗат эшчәнлеге башлана. 1939 елда Татарстан дәүләт нәшриятында яшь авторның «Яшел бөреләр» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә, тагын бер елдан (1940) «Үсәбез» дигән озын шигыре аерым китап булып басылып чыга.

Г.Галиев, 1939 елда хәрби хезмәткә алынып, Ватан сугышының беренче көннәреннән үк сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1941 елның сентябрь аенда Украинадагы Каменец-Подольский шәһәрен саклау өчен барган каты сугышларның берсендә ул батырларча һәлак була.

Г.Галиевнең әдәби мирасыннан аерым үрнәкләр 1961 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Алар сафта» исемле җыентыкта урын алган.

Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән солдат-шагыйрь буларак, Г.Галиевнең исеме Татарстан Язучылар союзы бинасына куелган мемориаль тактага язылды.



## Мансур Гаязов
(1917 – 1943)

Мансур Гаяз улы Гаязов 1917 елда хәзерге Мари АССРның Бәрәңге районы Бәрәңге авылында туа. Җиде классны тәмамлаганнан соң, Бәрәңге педагогия техникумында белем ала, аннары Бәрәңге урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.

1938—1940 елларда Кызыл Армиядә хезмәт итә, ә Бөек Ватан сугышы башлану белән фронтка китә, берничә тапкыр яралана, шунда КПСС сафларына член итеп алына. 1943 елның 19 ноябрендә Витебск өлкәсенең Ускорово авылы өчен барган каты сугышларда егерме алты яшьлек шагыйрь Мансур Гаяз батырларча һәлак була.

Мансур Гаяз — сугыш алды елларында әдәбият мәйданына килеп, кыска гына вакыт эчендә исемнәрен танытып өлгергән, ләкин, иҗат мөмкинлекләрен тулысынча ача алмыйча, Бөек Ватан сугышы фронтларында халыклар азатлыгы өчен гомерләрен биргән татар әдипләреннән берсе. Ул 1936 елда яза башлый. Алты еллык иҗат гомерендә чордашларының җанлы образларын, аларның уй-хисләрен сурәтләгән күп кенә лирик шигырьләр һәм «Тормышны сөю», «Испанка» кебек поэмаларын яза. Аның иҗатында патриотизм, илне саклау темасы зур урын алып тора. Иҗат эшчәнлеген ул сугыш шартларында да туктатмый: фронт газеталарында аның патриотик рухлы шигырьләре һәм очерклары басыла. Вакытсыз һәлак булган яшь шагыйрьнең сайланма әсәрләре 1959 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Шигырьләр» исемле җыентыгында тупланган.



Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән язучы-солдат буларак, Мансур Гаязның исеме Татарстан Язучылар союзы бинасына куелган мемориаль тактага язылды.



Әгъзам Камал
(1918 – 1943)

Әгъзам Камал (Әгъзам Камалетдин улы Камалетдинен) 1918 елның 21 январенда хәзерге Татарстанның Апас районы Үтәмеш авылында ярлы крестьян гаиләсенд, дә туа. 1932—1934 елларда үз авылларында җидееллык мәктәптә (ТБУМда) укый, аны тәмамлагач, Казанга килеп, финанс-экономика техникумында белем ала, 1937 елда техникумны тәмамлап, берникадәр вакыт Татарстаның Тәкәнеш районында үз белгечлеге буенча эшләгәннән соң, ул яңадан Казанга кайта һәм 1938—1939 елларда «Чаян» журналы һәм «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1939 елның көзендә, армия сафларына чакырылып, хәрби курсларны тәмамлагач, армиядә кече командир булып хезмәт итә.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк Әгъзам Камал алгы сызыкта сугыша. Канлы бәрелешләрнең берсендә яраланып, шактый вакыт госпитальдә дәвалана, аннары Саратов шәһәрендәге хәрби училищега укырга җибәрелә. Училищены офицер дәрәҗәсе алып тәмамлаганнан соң, Әгъзам Камал кабат үз частена — Сталинград фронтына кайта һәм андагы хәлиткеч сугыш операцияләрендә күп мәртәбәләр катнашып, 1943 елның 16 маенда дошман пулясыннан һәлак була.

Әгъзам Камал мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза башлый. Казанга килгәч, аның шигырьләре өлкә көндәлек матбугатында, альманахларда, күмәк җыентыкларда еш басыла. 1938 елда яшь шагыйрьнең «Җилфердә, байрак!» исемле (Әнәс Галиев белән бергә), ә 1939 елда «һәйкәл янында җыр» дигән шигырь җыентыклары басылып чыга. Аның поэзиясендәге төп тема — бәхетле совет чынбарлыгы. Ул совет батырларының Котыпны яулап алулары («Дүрт гражданин»), туган илне дошманнардан саклау горурлыгы («Сакта», «Комиссар турында җыр», «Командир»), ана бәхете («Ана») турында дәртләнеп яза, поэзиядәге остазлары Тукай белән Маяковскийга булган соклану хисләрен шигъри юлларга сала. Фронтның кырыс шартларында да Әгъзам Камал әдәби иҗат эшчәнлеген дәвам иттерә. Аның бу чорда язган шигырьләре фронт газеталарында, «Кызыл Татарстан»да һәм «Совет әдәбияты» журналында басыла.



Сугыштан соң шагыйрьнең әдәби мирасыннан үрнәкләр «Татар поэзиясе антологиясе»ндә (1956), «Җыр һаман яңгырый» (1956) һәм «Алар сафта» (1961) исемле җыентыкларда басылып чыкты. Шагыйрьнең аерым шигырьләре рус теленә дә тәрҗемә ителеп басылды. Әгъзам Камалның исеме Татарстан Язучылар союзы бинасына куелган мемориаль тактага язылды.



Муса Җәлил
(1906 – 1944)



Татар халкының бөек улы, герой шагыйрь Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елның 15 февралендә хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы Мостафа авылында дөньяга килә. 1913 елда Мусаның әтисе Мостафа абзый, ишле гаиләсен ияртеп, Оренбург шәһәренә күчә.

Муса алты яшеннән авыл мәктәбенә укырга керә, гаилә шәһәргә күчкәч, укуын «Хөсәения» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. Шигырьләр язып, аларны мәдрәсәдәге кулъязма журналга урнаштыра бара. Муса, бу мәктәпнең алдынгы укучыларыннан булып, озакламый шәһәр комсомол оешмасына член булып керә.

1919 елның октябрендә, Оренбург шәһәре Дутов гаскәрләре тарафыннан камап алынган чорда, «Кызыл йолдыз» газетасында унөч яшьлек М. Җәлилнең «Бәхет» исемле шигыре басылып чыга. Шуннан соң аның революция, көрәш рухы белән сугарылган романтик шигырьләре матбугат битләрендә еш күренә башлый. 1919 елның декабрендә М. Җәлил туган авылы Мостафага кайта һәм мәктәп балаларын, яшүсмерләрне бердәм оешмага туплау буенча культура-агарту эшләре алып бара. 1920 елның гыйнварында М. Җәлилнең актив катнашы белән Мостафа авылы яшьләренең комсомол ячейкасы төзелә. Шушы ук вакытларда ул, кулына корал алып, ирекле коммунарлар отряды составында кулак бандаларын тар-мар итү операцияләрендә катнаша. 1921 елның афәтле җәен М. Җәлил яңадан Оренбург шәһәрендә уздыра. Көзен аны, партиянең губерна комитеты рекомендациясе белән, Оренбург хәрби-партия мәктәбенә урнаштыралар. Алты айдан мәктәпне тәмамлагач, ул Халык мәгарифе институтына укырга керә, ләкин, авырып китеп, тиздән укуын ташларга мәҗбүр була. Аннан да бигрәк ул Казанга, татар мәдәниятенең үзәгенә ашкына.

1922 елның көзендә М. Җәлил Казанга килә. Башта ул «Татарстан» газетасы редакциясендә эшли, ә 1923 елдан Татрабфакта укый башлый. Рабфакта төрле фәннәрнең нигезләре белән танышу, алдынгы яшьләр, язучылар арасында кайнау М. Җәлилнең фикри үсешенә һәм иҗат активлыгына уңай йогынты ясый. Газета-журналларда аның бер-бер артлы шигырьләре, мәкаләләре басыла, 1925 елда исә «Барабыз» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә.

1925—1927 елларда М. Җәлил ВЛКСМның Орск өяз комитетында, аннары Оренбург губерна комитетында инструктор булып эшли. 1927 елда аны комсомолның Бөтенсоюз киңәшмәсенә делегат итеп җибәрәләр. Киңәшмәдә ул ВЛКСМ Үзәк Комитетының татар-башкорт секциясе бюросына член итеп сайлана һәм Мәскәүдә эшләргә калдырыла. Бюроның тапшыруы буенча М. Җәлил беренче татар совет балалар журналларын («Кечкенә иптәшләр» һәм «Октябрь баласы») оештыруда актив катнаша һәм 1932 елның ахырына кадәр («Октябрь баласы» Казанга күчеп, «Пионер каләме» исеме белән чыга башлаганчы) шул журналларның җаваплы редакторы булып эшли. Бер үк вакытта ул 1927—1931 елларда Мәскәү дәүләт университетының әдәбият-сәнгать факультетында укып югары белем ала. 1929 елда М. Җәлил партия сафына керә.

1933—1934 елларда М. Җәлил Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Коммунист» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли. Үзәк газеталарда эшләгән елларда ул, журналист-хәбәрче буларак, күп кенә промышленность предприятиеләренә, колхоз-совхозларга бара» халыкның тормышы һәм хезмәте белән якыннан таныша. Болар һәммәсе аның әдәби иҗатында билгеле бер чагылыш табалар. 1934 елда шагыйрьнең күп кенә шигырьләрен эченә алган шактый зур җыентыгы («Орденлы миллионнар») басыла һәм шул ук елны «Стихи Мусы Джалиля» исеме белән сайланма шигырьләре беренче мәртәбә рус телендә чыга.

1935 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында татар опера театрына профессиональ кадрлар әзерләү өчен Татар опера студиясе оештырылгач, М. Җәлилне шунда әдәби бүлек мөдире итеп эшкә чакыралар. Шагыйрь үзе өчен яңа бу хезмәткә дәртләнеп тотына, чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә опера сәнгатенең специфик үзенчәлекләрен, классик опера һәм балет либреттоларының язылу хасиятләрен профессиональ белгеч дәрәҗәсендә үзләштереп, студиядә зур оештыру эшләре алып бара: үз тирәсенә дистәләрчә шагыйрьләрне һәм композиторларны туплый, аларны сәнгатьнең катлаулы тармагында иҗат итәргә рухландыра, либреттолар язарга булыша, беренче татар операларының тууына турыдан-туры иҗади ярдәмен күрсәтә. 1938 елда студиядә укуын тәмамлап Казанга кайткач та М. Җәлил опера театрының әдәби бүлек җитәкчесе булып эшләвен дәвам иттерә.

Композиторлар белән аралашу, музыка дөньясы белән тыгыз бәйләнеш тоту Җәлил иҗатында яңа үзгәрешләр туугa сәбәп була: әсәрләрендә лирик җылылык, музыкальлек, нәфислек, халыкчан табигыйлек хасиятләре көчәя, җыр һәм романслар иҗат итүгә игътибар арта. «Сагыну», «Җир җиләгем», «Җырым булсын бүләгем», «Карашларың» кебек хисләрнең сафлыгы һәм тирәнлеге белән «аерылып торган шигырьләр, композиторлар тарафыннан музыкага салынып, халыкның яраткан җырларына әвереләләр. Әдипнең иҗатында бөтенләй яңа жанр—драматик поэма жанры да барлыкка килә. «Алтынчәч» (1935—1941), «Илдар» (1940) драматик поэмалары нигезендә композитор Н.Җиһанов соңыннан үзенең атаклы опералaрын иҗат итә.

М.Җәлилнең 1934—1941 еллар арасында язган лирик шигырьләре, җырлары, «Хат ташучы» (1938), «Алтынчәч» кебек поэмалары сугышка кадәрге татар совет поэзиясенең үзенчәлекле бер казанышы буларак тәкъдир ителәләр.

1939 елда М.Җәлил Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре итеп билгеләнә. Шул ук елны Казан хезмәт ияләре аны шәһәр советына депутат итеп сайладылар. Ватан сугышын ул шушы җаваплы постларда эшләгән җәмәгать эшлеклесе һәм күренекле әдип сыйфатында каршылый.

1941 елның июль аенда М. Җәлил армиягә алына. Башта ул Казан гарнизоны хәрби частендә рядовой кызылармеец булып хезмәт итә, аннары Курск өлкәсендәге политработниклар әзерли торган алты айлык курсларга укырга җибәрелә. Курск өлкәсенә фашист гаскәрләре якынлашкач, курслар Татарстанның Минзәлә шәһәренә эвакуацияләнә. 1941 елның декабрендә курсларны тәмамлагач, өлкән политрук М.Җәлил Мәскәү аша фронтка китә (февраль, 1942), Ул Төньяк-көнбатыш фронтта чыга торган «Отвага» исемле газетаның алгы сызыктагы хәрби корреспонденты итеп билгеләнә. 1942 елның июнендә Волхов юнәлешендә барган канлы сугышлар вакытында, аларның часте чолганышта калып, М. Җәлил каты яраланган хәлендә дошман кулына эләгә. Шул көннән патриот шагыйрьнең фашист тоткынлыгындагы газаплы һәм героик тормыш этабы башлана.

М. Җәлил һәм җәлилчеләрнең, яшерен оешма төзеп, фашизмга каршы алып барган героик көрәше, каһарманлыклары турында дистәләрчә китаплар — романнар, повестьлар драма әсәрләре һәм поэмалар язылган, кинофильмнар төшерелгән. Иң мөһиме: Җәлил һәм аның иптәшләре ахыргы сулышларына кадәр ватан алдында турылыклы булып калалар һәм фашизмга каршы көрәштә тиңдәшсез рухи ныклык, батырлык үрнәге күрсәтәләр.

1944 елның февраль аенда Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә Дрезденда суд була. Фашистик хәрби суд аларны, «дәүләткә каршы җимерү эше» алып баруда гаепләп, үлем җәзасына хөкем итә. Шул елның
25 августында Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилченең гомере өзелә.

1956 елның 2 февралендә СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән Муса Җәлилгә Ватан сугышы чорында күрсәткән тиңдәшсез ныклыгы һәм батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелде, ә әсирлектә тудырган поэтик иҗаты — бөтен дөньяга мәшһүр «Моабит дәфтәрләре» Ленин премиясенә лаек булды.







«Моабит дәфтәрләре» — Җәлил поэзиясенең иң югары ноктасы. Моабит шигырьләрендә шагыйрьнең шәхси образы, кичерешләре, фәлсәфи уйланулары аша кеше рухының бөеклеге, куркусызлыгы, гуманистик табигате, гаделлек һәм хаклык тантанасына якты ышанычы, туган иленә, туган халкына чиксез мәхәббәте гаҗәеп зур эмоциональ көч һәм сәнгатьчә камиллек белән гәүдәләнә.

Моабит шигырьләре шагыйрьне әдәбиятның бөтен дөнья орбитасына алып чыкты. Бу шигырьләр, СССРдагы барлык милли телләргә тәрҗемә ителүдән тыш, инглиз, француз, испан, немец, гарәп, япон, венгр, румын, чех, корея һәм башка чит ил халыклары телләрендә дә кат-кат басылдылар.
М.Җәлилнең әдәби мирасы күп милләтле совет әдәбиятының кыйммәтле бер казанышы булып тора. Аның әсәрләре кешеләрдә матур, гуманистик тойгылар уята, аларны тормыштагы матурлыкны күрергә һәм шул матурлык өчен көрәшергә чакыра.





## Җырларым

Җырларым, сез, шытып йөрәгемдә,
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе.
Шигыремдәге чынлык, ут һәм сөю—
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигыремдәге изге антыма.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш язына.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомерем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.









Нури Арсланов

(1912 – 1991)



Шагыйрь һәм тәрҗемәче Нури Газиз улы Арсланов 1912 елның 19 сентябрендә Казакъстандагы Петропавел (Кызылъяр) шәһәрендә туган. 1928 елда Күкчәтау шәһәрендә җидееллык татар мәктәбен тәмамлый, аннан, укуын дәвам итү теләге белән Казанга килеп, 1928—1931 елларда сәнгать техникумының рәсем бүлегендә укый. Техникумны тәмамлагач, 1933 елның көзенә кадәр башта Татарстанның Кукмара эшчеләр поселогында, аннары Урта Азиядә рәсем-сызым укытучысы һәм Ерак Көнчыгыш шәһәрләрендә художник-бизәүче булып эшли. 1933 елның сентябреннән - балалар журналы «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») һәм «Яшь ленинчы» газетасы редакцияләрендә рәссам хезмәтендә.

1934—1936 елларда, фин сугышы башлануы сәбәпле, Н.Арслановны яңадан хәрби хезмәткә чакыралар. У л махсус миномет батальоны составында ак финнарга каршы сугышта катнаша, сугышны фин шәһәре Сартавалада тәмамлый. Фронттан кайтып, редакциядәге эшендә ике елны тутырырга да өлгерми, сугышның тагы да афәтлерәге— Беек Ватан сугышы башлана. 1941 елның август аеннан 1946 елның июленә кадәр Н.Арсланов яңадан армия сафларында. Башта ул Ульяновск шәһәрендәге хәрби пехота училищесында укый, аннары рота командиры сыйфатында Төньяк-Көнбатыш фронтның Ржев шәһәре өчен барган канлы сугышларында катнашып, авыр яра ала һәм госпитальгә озатыла. Бөек Ватан сугышы чорындагы сугышчан хезмәтләре өчен Совет хөкүмәте аны Кызыл Йолдыз ордены (1942), «Батырлык өчен» медале белән бүләкли. Бөек Ватан сугышыннан соң Нури Арсланов ун елга якын «Совет Татарстаны» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә — рәссам, 1964—1972 елларда «Казан утлары» журналында поэзия бүлеге мөдире булып эшли. 1972 елда ул бөтенләе белән профессиональ язучылык хезмәтенә күчә.

Әдәбиятка Н. Арсланов «Мәхәббәт» (1942) һәм «Рус кызы» (1943) исемле поэмалары белән килеп керә. Шуннан соц аның шигъри таланты, осталыгы китаптан-китапка үсә-чарлана бара, иҗаты яңадан-яңа сыйфатлар һәм яңа темалар белән байый. Илленче елларда бетен дөньяда җәелгән тынычлык өчен көрәш, изелгән халыкларның милли азатлык хәрәкәтләре, сугыштан соңгы Татарстан тормышындагы социаль һәм әкономик узгәрешләр, нефть промышленносте барлыкка килүе — болар берсе дә шагыйрьнең игътибарыннан читтә калмый. «Ай Хян белән Ли» (1950), «Корея гөле» (1951), «Давыл кызы» (1954), «Яшьлек чишмәсе» (1954), «Көзге» (1955), «Тапкыр игенче» (1959) кебек терле халыкларның авыз иҗаты әсәрләреннән файдаланып язылган поэма-легендалар һәм поэма-әкиятләр, «Девон фонтаннары», «Якты юл», «Язгы яңгыр алдыннан» исемле шигырь жыентыклары, балалар өчен язылган «Ауда», «Сыерчык», «Карамаймалай әкияте» исемле китаплар һәм «Баулылар» (1950), «Көймәдә» (1957) кебек тиз вакыт эчендә халык арасында популярлашып киткән жырлары Н. Арслановның бу еллардагы иҗат диапазонын билгелиләр.

Алтмышынчы еллардан башлап Н. Арслановның шигърияте нигезендә яткан лирик-философик башлангычлар, ватандарлык, кешелеклелек хасиятләре тагы да тирәнәеп һәм яңа яклары белән ачылып, үзенчәлекле бер шигъри дөнья тудыруга китерә. Аның шигырьләрендәге фикер һәм хис тагы да тыгызлана төшә, аларның эмоциональ тәэсир иту көче бермә-бер арта. Заман турында, туган җир, халык язмышы турында фәлсәфи уйланулар рәвешендә зур поэтик осталык белән язылган күп санлы шигырьләре, «Монсар» (1966), «Горур Гайшә» (1967), «Диңгез ярында» (1967), «Романтика» (1969), «Майра» (1969) кебек лирик-философик поэмалары һәм бигрәк тә якты хисле мәхәббәт лирикасы Н.Арслановны бугенге татар поэзиясенең алгы сафында барган шагыйрь итеп таныта.

Татар халык иҗатын һәм классик әдәбиятын, Шәрекъ һәм төрки халыкларның поэзиясен тирәнтен белү Н. Арслановка үз иҗатында форма һәм тел-сүрәтләүнең яңа чараларын, төрләрен табарга, күп кенә гомумтөрки сүзләрне, традицион гыйбарәләрне шигырь тукымасына бик урынлы һәм табигый яңгырашында кертеп җибәрергә мөмкинлек бирә.

Шагыйрьнең күп кенә шигырьләре композиторлар тарафыннан музыкага салынган. «Республикам минем» (Н. Җиһанов), «Казан кызы» (З.Хәбибуллин), «Нәсимә» (З.Хәбибуллин), «Үрдәкләрем-дүдәкләрем» (И.Хисамов), «Гәрәбә» (Р.Гобәйдуллин) кебек җырларны татар жыр сәнгатенең матур үрнәкләре дип бәяләргә мөмкин.

Н.Арсланов тәрҗемә өлкәсендә дә иҗатының башлангыч чорыннан ук туктаусыз һәм нәтиҗәле эшләп килә. Пушкин, Лермонтов, Байрон, Гете, Шелли, Беранже, Хәйям, Хафиз, Мәхтүм Колый, Токтогул, Абай, Райнис, Гамзатов һәм башка бик күпләрнең поэтик әсәрләре аның тәрҗемәсендә татар телендә яңгырый.
Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Н.Арсланов Халыклар Дуслыгы (1982), Хезмәт Кызыл Байрагы (1971) һәм «Почет Билгесе» (1957) орденнары белән бүләкләнде.

Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Иделем-илем» (1982) исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы өчен Нури Арсланов 1985 елда Татарстан АССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.



## Походка киткәндә

Походка киткәндә күп газап чиксә дә,
Сыкранмый сугышчы йөрәге,
Дошманны бетерү, тынычлык китерү -
Шул аның кыйммәтле бүләге.





Салих Баттал
(1905 – 1995)





Салихҗан Вазих улы Батталов 1905 елның 5 августында элекке Казан губернасы Спас өязе (хәзерге Алексеев районы) Зур Тигәнәле авылында туган. Алты яшендә үзлегеннән укырга-язарга өйрәнә, соңыннан күрше Урта Тигәнәле авылы мәдрәсәсендә һәм гражданнар сугышы чорында бер кыш Чистай шәһәрендәге Шиһап хәзрәт мәдрәсәсендә укый. 1921 елгы кытлык вакытында урта хәлле крестьян хуҗалыгы тәмам бөлеп, хәлсезләнеп калгач, уналты яшьлек Салих, апасы һәм җизнәсенә ияреп, Мәскәү өлкәсенә үз көнен үзе күрергә чыгып китә. Ул төрле көнлекче эшләрдә эшли: совхоз һәм хосусый хуҗалыкларда икмәк, яшелчә җыеша, вагоннардан утын, күмер, торф бушатыша, җир казый, көтү көтә һ. б.

1924 елда, Мәскәү өлкәсендәге Соболево-Щелково туку фабрикасында эшләгәндә, фабрика янындагы татар клубы стена газетасында яшь егетнең В.И. Ленин үлеменә багышланган беренче шигыре «дөнья күрә». Тиздән шигырьне Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Эшче» газетасында да күчереп басалар. С. Батталның әдәби иҗат юлына аяк басуы әнә шулай башлана.

1924—1926 елларда С.Баттал татар-башкорт эшче яшьләренең Мәскәүдәге ике еллык гомуми белем курсларында укый. Бер ук вакытта шигырьләр язуын да дәвам иттерә. Алар шул замандагы Мәскәү татар көндәлек матбугатында даими басылып торалар. Курсларны тәмамлагач, С.Баттал Мәскәү өлкәсендәге Вербилка фарфор фабрикасында эшли башлый, төп хезмәте белән бергә, татар эшчеләре арасында мәгариф-агарту эшләрен оештыручы вазифасын да үти. Бераз соңрак (1928 елда) фабрикада эшләгәндә алган тәэсирләр нигезендә С.Батталның беренче сәхнә әсәре — «Организатор» исемле комедиясе языла. Комедия 1928—1929 елларда Мәскәү Үзәк татар эшче театры сәхнәсендә күп мәртәбәләр уйнала. Ул шулай ук башка театрларда да уңыш белән бара.

1927 елда С. Баттал Кызыл Армиясе хәрби һава көчләренең Ленинградтагы хәрби теория мәктәбенә укырга керә. Аны уңышлы тәмамлагач, укуын Оренбург очу мәктәбендә дәвам иттерә (1928—1929), аннан соң өч елдан артык Брянск һәм Казан шәһәрләрендә очучы булып эшли. Бу чорда язучының әдәби иҗаты да активлаша. 1929 елда СССР халыкларының Үзәк нәшриятында әдипнең «Еллар җыры» исемле беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга, ә колхозлашу чоры авылындагы сыйнфый көрәшне калку итеп сүрәтләгән «Язучы яулык» (1930—1931) драмасы Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела.

1933 елның язынннан 1934 елның ахырынача С.Баттал һава көчләренең махсус конструкторлык бюросы янындагы сынау отрядында хезмәт итә. 1935 елда исә, хәрби хезмәттән китеп, Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр нигездә әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Бу елларда аның күп санлы шигырьләре, поэмалары («Кешелек һәм күселек», 1933; «Очучылар турында баллада», 1935; «Авиа-марш», 1940 һ. б.), проза әсәрләре («Очучылар» романы, 1935) һәм «Сынау» (1938) исемле пьесасы языла. Соңгысы 1939 елда Татар дәүләт академия театрында куелып, әдәби тәнкыйтьнең уңай бәясенә лаек була. Ул шулай ук аерым китап булып та басылып чыга. Ватан сугышы чорында Салих Баттал Хәрби Һава Көчләренең Тын Океан флотында хәрби очучы булып хезмәт итә (1941—1945), япон империялистларына каршы сугышларда катнаша, шәхси батырлыклары өчен сугышчан медальләр белән бүләкләнә. Сугыш елларында әдип партиотик рухтагы шигырьләр һәм «Капитан Гастелло» (1942) исемле поэмасын яза.

Салих Батталның сугыштан соңгы иҗат эшчәнлеге күләмле поэтик әсәрләре белән характерлы. Алар арасында «Олы юл буйлап» («Газзә», 1953) шигъри повесте язучы иҗатының гына түгел, гомумән илленче еллардагы татар совет поэзиясенең күренекле әсәрләреннән саналырга хаклы. Сугыштан соңгы авыл тормышын драматик ситуацияләрдә яктырткан бу повесть шул ук елны рус теленә тәрҗемә ителә һәм «Новый мир» журналында басылып чыга. Шагыйрьнең күләмле эпик әсәре — «Чирмешән якларында» (1934—1970) исемле шигъри романы да игътибарга лаек.

Сугыштан соңгы чорда әдип драматургия һәм проза жанрларында нәтиҗәле эшли. Аның драматик әсәрләреннән әхлак-этика мәсьәләләренә багышланган «Бер карар тирәсендә» (1950), «Киртә» (1959), «Яда өйгә кучкәч» (1959), «Үтеп барышлый» (1960), «Бәрәкәтле чәй» (1969) кебек пьесаларын күрсәтеп үтәргә мөмкин. Проза жанрында С. Баттал үзенең балаларга атап язылган «Очучы язмалары» (1951) китабы һәм «Сигезенчесе кем?» (1965), «Баштан үткәннәр» (1972) исемле повестьлары белән билгеле. «Сигезенчесе кем?» повестенда совет иле төзелешенең иң киеренке чорлары — беренче бишьеллыклар һәм Бөек Ватан сугышы чоры фонында бер очучының катлаулы язмышы тасвирлана. «Баштан үткәннәр» дигән автобиографик әсәрдә исә автор, узган гомеренең беренче яртысына күзәту ясап, туган җир һәм чор турында уйлануларын, В. Чкалов, А. Фадеев, Г. Ибраһимов кебек күренекле замандашлары белән очрашуларын яза.

С.Баттал әдәби тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнә. Ул А.Пушкинның күп кенә шигырьләрен һәм «Поп һәм хезмәтче Балда турында әкият»ен, В.Маяковскийның «Владимир Ильич Ленин» поэмасын, шулай ук рус совет язучысы Н. Никитинның «Төньяк Аврора» исемле күләмле романын тәрҗемә итте.

Әдәбиятны үстерүдәге хезмәтләре өчен Салих Баттал Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде (1957).



# Нур Гайсин
(1914 – 1995)

Нурулла Әхьяр улы Гайсин 1914 елның 2 ноябрендә хәзерге Башкортстан АССРның Чакмагыш районы Әхмәт авылында туган. Җиде яшеннән ул әти-әнисез кала һәм чит кеше кулында тәрбияләнә. Авылда башлангыч белем ала. 1930 елда Уфадагы телеграфистлар курсын тәмамлагач, ике ел Башкорстанның Баймак районында телеграфист һәм Зилаир орлыкчылык совхозында элемтә бүлеге мөдире булып эшли. 1933 елда Башкортстан Үзәк Башкарма Комитеты тәкъдиме белән аны Татарстанның Зөя шәһәренә төзелеш институты рабфагына укырга җибәрәләр. Шунда укыганда Н.Гайсин әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый.

1934 елда Казандагы су юлы инженерлары әзерли торган институт рабфагында, аннары Казан педагогия институтының хәзерлек курсларында укый. Педагогия институтында укыган елларында яшь шагыйрьнең «Ватаным өчен», «Яшьлек таңы» исемле беренче шигырь җыентыклары басылып чыга.

1940—1941 елларда Н.Гайсин Татарстанның Ютазы районы Кәрәкәшле урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Бөек Ватан сугышы башлангач, армиягә алынып, башта зенитчы артиллеристлар курсында укый, ә 1942 елның апреленнән сугыш беткәнчегә кадәр һава оборонасы гаскәрләрендә взвод һәм батарея командиры булып хезмәт итә. Фронтта чакта, 1944 елның сентябрендә, ул КПСС сафларына член итеп алына.

1945 елның декабрендә армиядән кайткач, Н.Гайсин бераз вакыт Уфада «Кызыл таң» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, 1946—1952 елларда Казан татар театр училищесында директор урынбасары булып эшли. 1952— 1953 елларда яңадан Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1955 елдан язучылык эше белән генә шөгыльләнә.

Н.Гайсинның ике дистәгә якын шигырь һәм проза китаплары басылып чыга. Әдипнең яшьләргә багышланган «Давыллы көннәрдә» (1947) «Айсылуның мәхәббәте» (1947), «Юл ачык» (1950), пионер сәхнәләре өчен «Гаилә киңәшмәсе» (1952), «Ялгышу» (1968), «Югалган макет» (1967) кебек драма әсәрләре дә бар. 1981 елда Н.Гайсинның автобиографик материалга нигезләп язган проза әсәре — «Кызыл ыштанлы малай» исемле документаль повесте дөнья күрде.





Шамил Гәрәй
(1916 – 1946)

Шамил Гәрәй (Шамил Мөхәммәтгали улы Гәрәев) 1916 елның 31 декабрендә Казан шәһәрендә туа. Бик яшьли әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Җиденче класста укыган чагында, 1931 елда, «Яшь ленинчы» газетасында аның балалар өчен язган беренче шигыре басылып чыга, тагын бер елдан «Сигналчы җыры» исемле китабы дөнья күрә. Шуннан соң, чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә (1933—1941), Шамил Гәрәй янә дүрт шигъри Җыентыгын бастыра. Нигездә яшьләргә һәм балаларга багышланган һәм тематик яктан туган ил, бәхетле балачак, табигать турындагы мотивларны үз эченә алган бу шигъри китаплары белән Ш.Гәрәй өметле шагыйрь булып таныла. Ул шулай ук әдәби тәрҗемә эше белән дә актив шөгыльләнә: «Азат Хатын», «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын) журналларында аның тәрҗемәсендә А.Чехов хикәяләре, М.Лермонтов шигырьләре, украин фольклорыннан үрнәкләр һәм аерым басма булып Л.Квитконың «Бишек җыры» (1940)9 А.Бартоның «Уенчыклар» (1941) исемле китапчыклары басылып чыга.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, Ш.Гәрәй фронтка китә. Мәскәү янында барган каты сугышларның берсендә чолганышта калып, ул фашистлар кулына эләгә һәм фашизм коллыгының бөтен авырлыкларын кичерә. Җиңү көнен күрсә дә, зиндан тормышы аның сәламәтлеген какшата: 1946 елда Шамил Гәрәй вакытсыз вафат була.

Сугыштан соңгы чорда Шамил Гәрәй шигъри мирасының үрнәкләре «Алар сафта» (1961) исемле күмәк җыентыкта һәм «Татар балалар поэзиясе антологиясендә (1980) басылып чыкты.

Ватан азатлыгы өчен гомерен биргән әдип-солдат буларак, Ш.Гәрәйнең исеме Татарстан Язучылар союзы бинасына куелган мемориаль тактага язылды.





# Әнвәр Давыдов

(1919 – 1968)



Әнвәр Мортаза улы Давыдов 1919 елның 21 мартында Куйбышев өлкәсенең Камышлы авылында туа. Ул бик иртә укый-язарга өйрәнә, дүрт-биш яшьләрендә инде Тукайның балалар өчен язган шигырьләрен һәм башка әдәби китапларны укый башлый. Җидееллык мәктәпне тәмамлауга, аны, башка классташлары белән бергә, 1931 елда Камышлыда эшли башлаган авыл хуҗалыгы техникумының беренче курсына күчерәләр. Ләкин Әнвәргә анда тоташтан укырга туры килми: 1928 елда әтисе, ә 1931 елда фаҗигале рәвештә уртанчы абыйсы үлгәннән соң, гаиләнең материаль хәле шактый авырая, һәм йортта бердәнбер ир кеше урынына калган Әнвәр, техникумдагы укуын бүлә-бүлә, ел саен диярлек төрле вакытлы эшләргә ялланып, семьяга ярдәм итәргә мәҗбүр була.

Поэтик тәҗрибәләрен Ә.Давыдов бик иртә башлый. Унике яшендә чагында Камышлы район газетасында аның беренче шигыре басылып чыга («Коммунага», 1931 ел, 14 март саны). Шул ук елларда «Октябрь баласы» (Мәскәү) журналында авыл пионерларының күмәк уеннары хакындагы очеркы да дөнья күрә.

1936 елның азагында, олы абыйсы, заманының танылган журналисты Мирза Давыдов (1898—1943) чакыруы буенча, Ә.Давыдов Новосибирск шәһәренә китә һәм анда чыга торган «Советская Сибирь» исемле газета редакциясенә әдәби хезмәткәр булып эшкә урнаша. Ике елдан Үзбәкстанга күчеп, Фирганә шәһәрендә башта өлкәнең рус, аннан үзбәк газеталарында эшли. I939 елда, авырып китеп, врачлар киңәше белән, кире туган якларына кайта һәм, 1939—1940 уку елында Мордва АССРның Ләмбрә (хәзерге Ромадан) районы Белозерье авылы җидееллык мәктәбендә рус теле һәм тарих укытучы булып эшли.

1940 елны аны Совет Армиясенә алалар. Башта ул Монголия чиге буенда хезмәт итә, аннан 1941 елның апрель—май айларында Көнбатыш чикләргә таба юл тотып, сугыш башлануга фронтның үзәгенә барып эләгә.


Ә.Давыдов Бөек Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр рядовой солдат, аннан кече командир — сержант сыйфатында сугышчан юл үтә, Волхов Ленинград янындагы, Балтик буе республикаларындагы канлы сугышларда катнаша. Фронтта 1942 елда КПСС сафларына член булып керә.

Армиядән кайткач (1946), Ә.Давыдовны Камышлы район газетасына («Югары уңыш өчен») җаваплы редактор итеп билгелиләр. Бер үк вакытта ул янып-илһамланып иҗат эше белән шөгыльләнә: шигырьләр, поэмалар яза, район газетасы битләрендә көннең кадагына суккан фельетоннарын, сатирик шигырьләрен бастыра. 1948 елда яшь язучыларның Казанда уздырылган конференциясендә (28 ноябрь) Ә. Давыдовның «Коммунизм таңы» колхозында» исемле поэмасы уңай бәя ала, һәм 1949 елда әсәр басылып та чыга («Совет әдәбияты», № 4). Аннан «Алтын көз» поэмасы дөнья күрә. 1950 елда исә шагыйрьнең «Беренче бөртек» исемле поэмалар һәм шигырьләр җыентыгы басыла.

1952 елда Ә.Давыдов бөтенләйгә Казанга күчеп килә. 1953—1955 елларда ул Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре булып эшли, 1954—1957 елларда идарә члены, берничә ел шагыйрьләр секциясенең җитәкчесе булып тора.

Әнвәр Давыдов чагыштырмача кыска гомере эчендә (ул, кырык тугыз яшендә, 1968 елның 23 июнендә Казанда вафат булды) бай әдәби мирас калдырган шагыйрь. Үзе исән чагында татар һәм рус телләрендә аның егерме өч шигъри җыентыгы һәм М.Җәлилгә багышланган документаль повесте басылып чыга.

«Дәверләр диалогы» исемле күләмле җыентыгы инде шагыйрь үлгәннән соң, 1969 елда дөнья күрә. Соңыннан, шагыйрьнең архивын барлаганда, аның кулъязма хәлендә тагын бер әсәре — «Йокысыз төннән соң» исемле зур күләмле шигъри романы табыла. Бу әсәр 1972 елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан аерым китап итеп чыгарылды һәм рус теленә дә тәрҗемә ителде.





Нәби Дәүли

(1910 – 1989)



Нәби Дәүли (Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин) 1910 елның 1 июнендә хәзерге Татарстанның Әлки районы Иске Камка авылында туган. Нәбиуллага сабый чактаң ук тормышның бөтен ачысын татырга туры килә: дүрт яшендә чагында аның әтисе үлә, ә әнисе, Ставрополь (Төньяк Кавказ) якларында батраклыкта йөргән Хәйрулла Дәүләтшин дигән кешегә янә кияүгә чыгып, өч баласы белән шул якларга күченеп китә. Берникадәр вакыттан соң үги әти белән әни кеше, авылдагы йорт-җирне сатып килү нияте белән, яңадан туган авылларына кайталар. Шунда Нәбиулланың әнисе дә кинәт вафат була, ә үги әти ятим балалар янына кире әйләнеп килми. Шулай итеп Нәбиулла чит-ят җирдә япа-ялгыз торып кала.

1921 елда хәзерге Волгоград шәһәренә килеп балалар колониясенә эләгә. Шунда җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары «Красный Октябрь» заводы каршындагы ФЗӨ мәктәбендә укый. Бераздан ул Донбасска китә һәм Донецк шәһәрендәге металл эшкәртү заводында тимерчелек һөнәренә өйрәнеп, цехта эшли башлый. Бер үк вакытта ФЗӨ мәктәбендә укуын да дәвам иттерә. 1928 елда Н. Дәүли Әстерхан шәһәренә укырга җибәрелә. Ләкин яңадан Донбасска кайта һәм мартен цехында шлакчы булып эшли. Шушы елларда ул Донбасста татар шахтерлары өчен чыгарыла торган «Пролетар» газетасында язышa башлый: хәбәрләр, шигырьләр, очерклар бастыра. Соңга таба ул үзе дә шушы газета редакциясенә әдәби хезмәткәр булып эшкә керә һәм армия хезмәтенә алынганчы шунда эшли.

1931—1933 елларда Винница шәһәрендәге полк мәктәбен тәмамлаганнан соң, Н. Дәүли старшина чинында Кызыл Армиянең Ерак Көнчыгыштагы чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә. 1935 елда Н. Дәүли Казанга килә һәм Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. 1937—1941 елларда аның дүрт шигырь җыентыгы басылып чыга («Бәхет», «Ал чәчәк», «Уйлар», «Кырык шигырь»). Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк, 1941 елның 26 июнендә, Нәби Дәүли фронтка китә. Ләкин аңа озак сугышырга туры килми, шул ук елның август аенда, Орша шәһәре тирәсендә барган авыр сугышларның берсендә чолганышта калып, ул фашистлар кулына эләгә.

1942 елның яз башында аны, бүтән әсирләр белән бергә, Германиягә озаталар. Башта ул берничә ай Бухенвальдта тотыла, аннары Баден-Баден, Магдебург шәһәрләре янындагы лагерьларда газап чигә. 1945 елның апрелендә, совет гаскәрләре Магдебургка якынлашып килгәндә, Н. Дәүли берничә иптәше белән лагерьдан кача һәм, фронт сызыгын үтеп, үзебезнекеләргә кушыла. Сугышның соңгы айларында ул Совет Армиясе сафында солдат хезмәтен дәвам иттерә.

1945 елның декабрендә Н. Дәүли Казанга кайта һәм 1956 елга кадәр шәһәрнең төрле художество мастерскойларында художник-бизәүче булып эшли 1956 елдан ул язучы-профессионал сыйфатында фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Нәби Дәүлинең сугыштан соңгы чор әдәби иҗаты жанр төрлелеге һәм з манга аваздаш ачык гражданлык пафосына сугарылган булуы белән үзенчә Җир язмышы, җирнең бүгенгесе, киләчәге өчен борчылу, тынычлык, к өчен көрәш, шул юлда корбан булганнарга дан җырлау, гади хезмәт кешесенең бөеклеген һәм акылын биеккә күтәрү, тормышта очрый торган һәртөрле житешсезлекләргә, гаделсезлекләргә карата килешмәүчәнлек һәм, ниһаять, халыкара сугыш кабызучыларны, кеше гомерен талап яшәүче тираннарны фаш итү — менә болар әдипнең бу чор иҗатындагы төп тематик эчтәлекне тәшкил итә. Бу темалар аның күп санлы лирик, публицистик, сатирик шигырьләрендә, баллададаларында, мәсәлләрендә, шигъри парчаларында, «Берлинда окоп» (1956), «Авыл дәфтәре» (1954—1967) кебек күләмле поэмаларында һәм прозасында чагылыш таба. Әдипнең проза әсәрләреннән «Яшәү белән үлем арасында» (1958) дигән повесте һәм «Җимерелгән бастион» (1965) исемле романы укучылар арасында аеруча популярлык казана. Автобиографик материалларга һәм сугыш чорындагы шәхси кичерешләргә нигезләп язылган бу документаль әсәрләр совет кешеләренең теләсә нинди авыр сынаулар кичкәндә дә көчле рухлы булып калуларын раславы һәм конкрет материал җирлегендә фашизмның антигуманистик йөзен, ерткычлыгын фаш итүе белән әһәмиятле.

Нәби Дәүли курчак театры өчен пьесалар, хәзерге тормышның төрле мәсьәләләрен яктырткан публицистик мәкаләләр, кечкенә күләмле проза әсәрләре—хикәя, нәсер, юмореска, фельетон, истәлек язмалары авторы буларак та укучыларга таныш.

Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Нәби Дәүли «Почет Билгесе» ордены (1980) һәм Татарстан Верховный Советы Президиумының Мактау грамоталары белән бүләкләнде.



Әнәс Галиев
(1920 – 1996)

Шагыйрь һәм прозаик Әнәс Касыйм улы Галиев 1920 елның 3 апрелендә Арча районы Кушлавыч авылында туган. Җидееллык авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1936—1939 елларда Казан финанс-экономика техникумында махсус белем ала, аннары инспектор булып эшли.

1940 елда Кызыл Армия сафына чакырыла һәм Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтның алгы сызыгында була. 1942 елның сентябрендә, Майкоп шәһәре тирәсендә барган канлы бәрелешләр вакытында, артиллерист Ә.Галиев, чолганышта калып, «контузияле хәлдә дошман кулына әсир төшә һәм 1945 елның апреленә кадәр (союздаш гаскәрләр тарафыннан азат ителгәнче) фашистлар тоткынлыгының бөтен авырлыкларын, газапларын үз башыннан кичерә, шунда үпкә авыруы эләктерә. Әсирлектән котылып, берничә ай эвакогоспитальләрдә дәвалангannaн соң ул, аякка басып, яңадан Казанга кайта һәм тыныч тормыштагы хезмәтен дәвам иттерә.

Ә.Галиевнең беренче шигырьләре 1937 елда «Кызыл яшьләр» газетасында басыла, ә 1938 ел һәм 1940 елларда «Җилфердә, байрак!», «Сөю» исемле шигырь китаплары дөнья күрә. Коточкыч кыен шартларга килеп эләгүенә карамастан, әдип фашист тоткынлыгында да үзенең иҗат эшен дәвам иттерә, шәхси кичерешләрен шигырь юлларына теркәп барырга тырыша. Бу шигырьләрнең бер өлеше 1958 елда «Кыен юл» исеме белән Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыга.



Алтмышынчы еллардан башлап Ә.Галиев нигездә проза жанрында иҗат итә. Газета-журналларда басылган бер төркем хикәяләреннән («Отпускыда» «Солдат язмышы», «Сәяхәт», «Күченер алдыннан», «Беренче очрашу», «Сагыну» һ. б.) тыш, ул бигрәк тә үзенең күләмле ике әсәре — автобиографик характердагы «Йолдызлар шаһит» һәм финанс оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр тормышын яктырткан «Намус кушканча» исемле повестьлары белән танылды.



# Әхмәт Ерикәй
(1902 – 1967)



Әхмәт Ерикәй 1902 елда Башкортстанның Өлкенде авылында крестьян гаиләсендә туа. Җиде балалы ишле гаиләгә тормыш итү авыр булганлыктан, Әхмәткә кечкенәдән үк тормыш ачысын татырга туры килә: кышларын авыл мәктәбенә укырга йөрсә, җәйләрен көтү көтә, авыл байларында көнлекче булып эшли, үсә төшкәч, әтисенә ияреп, Златоуст, Нязепетровск, һ.б. шәһәрләргә яллы эшләргә чыгып йөри. Бер үк вакытта күп укый, поэзия белән кызыксына, рус телен ярыйсы үзләштерә. 15 яшендә волость башкарма комитетында сәркатип булып эшли. Шушы елларда аның матбугат битләрендә беренче шигырьләре күренә башлый. 1927 елда Ә.Ерикәй Мәскәүгә килә һәм Дәүләт журналистика институтына укырга керә. Студентлык чорында төрле газета–журналларга язышa, «Эшче» газетасы редакциясендә җаваплы сәркатип һәм редактор урынбасары вазифаларын үти.
1932–1935 елларда Гослитиздатның СССР халыклары әдәбияты секторында редактор, сектор мөдире, Татарстанның Чистай районы МТСында политбүлек газетасы редакторы хезмәтләрендә була.
1935 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында татар опера театры студиясе ачылганнан соң, студиянең әдәби бүлек мөдире М.Җәлил белән беррәттән, Ә.Ерикәйне дә татар телендә либреттолар һәм җырлар язу эшенә тарта. 1935–1941 елларда Ә. Ерикәй «Шауласын, гөрләсен безнең җыр», «Комсомолка Гөлсара», «Гармун», «Яшь егетләр, яшь кызлар», «Тагын килер язлар», «Тын бакчада», «Туган ил», «Бибисара», «Кәккүк», «Алсу», «Минзәлә» һ.б. иҗат итә.
Бөек Ватан сугышы елларында Ә.Ерикәй фронт газетасында хезмәт итә, совет сугышчыларын фашизмга каршы көрәшкә өндәгән шигырьләр, очерклар һәм җырлар яза.
Сугыштан соңгы чорда шагыйрьнең иҗат активлыгы тагы да арта. Ул поэмалар, лирик шигырьләр, мәсәлләр, дүртьюллыклар, җырлар, мәкаләләр яза, тәрҗемә итә. Ләкин аны үзенчәлекле шагыйрь итеп танытканы – кыска лирик шигырьләр һәм җырлар. Җыр итеп язылган шигырьләре халыкчан шигъри бизәкләр, тапкыр сүзләр, чорга хас иҗтимагый фикер-хис белән сугарылган. Аларның ритмик төзелеше, эчке аһәңе үзеннән–үзе көйне сорап тора, шуңа күрә композиторлар Әхмәт Ерикәй поэзиясенә еш мөрәҗәгать итәләр. 1982 елда шагыйрьнең җырлары аерым китапка тупланып «Ике йөз җыр» исеме белән басылып чыкты.
Ә.Ерикәй 1967 елның 15 сентябрендә Мәскәүдә вафат булды.



Әхмәт Исхак
(1905 – 1991)



Татар совет поэзиясенең олы буын вәкилләреннән Әхмәт Исхак 1905 елның 1 маенда Казан шәһәрендә туган. Аның әтисе Габдулла абзый, гомере буе шәһәр байларына хезмәт итеп, улы Әхмәт туганда сәүдәгәр Галиевләрнең күн аяк киемнәре фирмасында кондорщик булып эшли торган була. Заманының шактый яңача карашлы кешесе буларак, ул үз балаларының укып белем алуларын тели һәм Әхмәткә җиде яшь тулуга, аны татарның ул вакыттагы алдынгы мәдрәсәләреннән саналган «Мөхәммәдия»гә бирә. Әхмәт монда Бөек Октябрь революциясенә кадәр укый,

1919 елдан исә Казанда яңа ачылган Татар педагогия техникумында укуын дәвам иттерә. 1922 елда техникумны тәмамлаганнан соң, комсомолның Татарстан өлкә комитеты янындагы матбугат бүлегендә экспедитор, соңыннан экспедициянең мөдире булып эшли. Шушы елларда ул, революция алып килгән социаль үзгәрешләр белән рухланып, шигырьләр яза башлый. Унсигез яшьлек егетнең революцион пафос белән сугарылган «Кызыл кошлар» исемле беренче шигыре 1923 елда «Кызыл Шәрекъ яшьләре» журналында басыла. Шуннан соң аның шигъри әсәрләре һәм төрле темаларга язган публицистик мәкаләләре, очерклары республика көндәлек матбугатында еш күренә башлый. 1925 елда Таткино оешмасы Ә. Исхакны Мәскәүгә Дәүләт кино техникумының сценарий бүлегенә укырга җибәрә. Ләкин шул ук елны техникумның сценарий бүлеге бетерелү сәбәпле, ул укуын ташларга мәҗбүр булып, Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Эшче» газетасы редакциясенә әдәби хезмәткәр булып эшкә керә. Монда эшләгәндә Ә. Исхак Мәскәүдә яшәүче татар әдипләре, шул җөмләдән Муса Җәлил белән якыннан таныша, алар арасында ныклы иҗади дуслык урнаша. Бер үк вакытта ул Мәскәү пролетар язучылары ассоциясенең (МАППның) татар секциясенә член итеп кабул ителә. Яшь шагыйрьнең бу чорда иҗат иткән шигъри әсәрләре «Таш урамнар җыры» исемле җыентыкка тупланып, 1929 елда СССР халыкларының Мәскәү Үзәк нәшриятында басылып чыга.

1928 елда Әхмәт Исхак яңадан Казанга кайта һәм «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасы редакциясендә техник секретарь булып эшли башлый. Соңрак, 1939 елга кадәр, шул ук редакциядә газетаны чыгаручы редактор, әдәби сотрудник, тышкы һәм эчке информация бүлеге мөдире, җаваплы секретарь урынбасары һәм җаваплы секретарь булып эшли. Бер үк вакытта «Чаян» журналы редакциясенең әдәби сотруднигы, җаваплы секретаре вазифаларын үти. 1939 елдан 1942 елга кадәр ул СССР Әдәби фондының Татарстандагы вәкиле булып тора.

1942 елның язында Әхмәт Исхак армия сафларына алынып, хәрби пехота училищесына җибәрелә. Шул ук елны уку курсын тәмамлагач, Ерак Көнчыгыштагы һәм Украинадагы хәрби частьларда взвод командиры булып хезмәт итә. 1945 елның августында аны «Родина зовет» исемле дивизия хәрби газетасына әдәби хезмәткәр итеп күчерәләр. Ул шунда 1945 елның декабренә кадәр хезмәт итә. Армиядә чагында, 1945 елның мартында, Ә.Исхак КПСС сафларына член итеп алына.

1963—1967 елларда «Чаян» журналының баш редакторы булып эшләвен исәпләмәгәндә, сугыштан соң Ә. Исхак үзен тулысы белән иҗат эшенә багышлый. Бу еллар эчендә шагыйрьнең татар, рус телләрендә утыздан артык китабы дөнья күрә. Алар арасында төрле жанр әсәрләре — шигырь һәм поэма, сатира һәм мәсәл җыентыклары, шигъри тупланмалар, балалар өчен язылган әкиятләр, либреттолар, Г.Тукай, М. Җәлил турындагы әдәби-гыйльми китаплар бар. Бу басмалар әдипнең халык, ил тормышы белән һәрвакыт тыгыз элемтәдә яшәвен һәм чорның барлык әһәмиятле вакыйгаларына шагыйрь һәм язучы буларак үзенең мөнәсәбәтен белдереп барырга тырышуын ачык күрсәтәләр. Аның шигъри таланты бигрәк тә публицистик лириа, сатира һәм мәсәл жанрларында ачык күренә. Шулай ук аның әдәби тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләре дә ифрат күп. Русчадан һәм башка милләтләр теленнән татарчага ул йөз мен юлдан артык шигырь һәм поэмалар тәрҗемә итә. Алар арасында А.Пушкиннын «Балыкчы һәм балык турында әкият»е, «Руслан һәм Людмила» поэмасы, «Евгений Онегин» романының, беренче өч бүлеге, М.Лермонтовтан «Демон», «Мцыри», «Боярин Орша», «Бородино» поэмалары һәм шигырьләр, Н. Некрасов, В.Маяковский, Н.Тихонов, С.Щипачев, К.Симонов, А.Сурков шигырьләре һәм поэмалары, И.Крылов, С. Михалков мәсәлләре, Көнчыгыш, төрки халыклары поэзиясеннән Г.Нәвоинын «Фәрһад вә Ширин» поэмасы, Җамбул, Абай, Мәхтүм Колый, Низами, Нәсими һәм Кәминәләрнен әсәрләре һәм башкалар бар. Татар поэзиясенең чишмә башы —XIII гасыр Идел буе шагыйре Кол Галинең биш мең юллы мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» поэмасын хәзерге татар әдәби теленә күчерүгә дә ул үзеннән зур өлеш кертте. 1985 елда Ә. Исхакның төрле милләт шагыйрьләреннән эшләгән сайланма тәрҗемәләре тупланган «Илһамнар чишмәсе» исемле күләмле китабы басылып чыкты.

Хәрби һәм әдәби хезмәтләре өчен Әхмәт Исхак Хезмәт Кызыл Байрагы (1955), Халыклар Дуслыгы (1970) орденнары һәм «1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» медале (1945) белән бүләкләнде.

Юк, кермәбез һичкайчан без богауларга!

Юк, йөрмәбез хурлык кигән йөкне

тартып!

Яшәгәнче башны иеп дошманнарга,

Без беләбез: күкрәк киереп үлү артык.

«Бер адым да чигенмәбез».

Борчылмагыз, дуслар, намус белән

Без үтәрбез Ватан кушканны,

Һәм үтәрбез илнең чикләреннән,

Тар-мар итеп явыз дошманны.

«Сугышчылар жыры».

**Чәчәк һәм үч**

Әзерләнеп тиздән җәелергә,

Һәм хуш исен җиргә сибәргә,

Үсеп утыра иде төнге чәчәк,

Иркәләнеп җылы җилләргә.

..........................................

Узып бара иде шул вакытта

Куаклыктан төнге юлына.

Кеше сынлы, ләкин ерткыч бер җан,

Автоматын тотып кулына.

Көтмәгәндә гүзәл бу чәчәккә

Китереп басты аның итеге.

Сытылып калды чәчәк һәм югалды

Ай уйнаган дымның бөртеге.

...........................................

Үч алыныр! Ләкин моның белән

Ачу сүнмәс күкрәк эчендә:

Үч алырбыз без ул бандитлардан

Сытылып калган чәчәк өчен дә!

1942.



Хисам

Камалов

(1926)



Хисам Нуретдин улы Камалов 1926 елның 14 апрелендә Татарстанның Әлмәт районы Кама-Исмәгыйль авылында туган. 1940 елда җидееллык мәктәпне тәмамлагач та туган авылының күмәк хуҗалыгында эшли башлый: җир сөрә, тырмага йөри, чәчү чәчә, атлар карый.

1943 елның ноябрендә унсигез яше дә тулмаган үсмер егетне гаскәри хезмәткә алып, 1944 елның апреленә кадәр мәгълүм Суслонгер-Сурок хәрби лагерьларында хәзерлек курслары үткәннән соң, май башында туп-туры фронтка озаталар. Ул Икенче Балтыйк буе фронты гаскәрләре составында бик күп канлы бәрелешләрдә катнаша, 1944 елның җәендә яраланып, өч ай чамасы госпитальдә ятып чыга, аннары яңадан фронтның алгы сызыгына җибәрелә, артиллерия полкының кыр элемтәчесе сыйфатында Латвия җирләре аша Польша чикләренә кадәр сугышчан юл уза. 1945 елның 26 февралендә Х. Камалов кабат яралана һәм янәдән госпитальгә озатыла. Бу юлы җәрәхәт бик җитди булып, егеткә ел ярым төрле госпитальләрдә дәваланырга туры килә, ахырда бер аягын төптән кистереп, 1946 елны ул инвалид булып өенә кайта.

Шул ук елны Х.Камалов Татарстанның Бөгелмә шәһәрендәге педагогия училищесында укый башлый, училищены тәмамлагач, Казанга килеп, 1950—1954 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укуын дәвам итә. Аннан унике ел дәвамында Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә мөхәррир булып эшли. 1967 елдан башлап ул — язучы-профе-сионал, фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Х.Камалның беренче әдәби иҗат тәҗрибәләре студент елларына туры килә. Педагогия институтында укыганда ул институттагы һәм республика яшьләр газетасы редакциясе каршындагы әдәби түгәрәкләргә йөри. Тәүге басма шигырьләре дә әлеге яшьләр газетасы битләрендә дөнья күрә. Соңга таба «Казан ут лары» журналын да һәм башка матбугат басмаларында катнаша башлый. 1955 елда «Яңадан сафка» исемле беренче мөстәкыйль китабы, ә тагы бер елдан «Чияле тау» дигән икенче җыентыгы нәшер ителә. Шушы тәүге китапларындагы шигырьләрендә үк шагыйрьнең бөтен иҗатына хас темалар һәм сурәтләү үзенчәлекләре ачык билгеләнә. Аның игътибар үзәгендәге темалар — Ватан сугышы, Туган җир, Туган авыл, аның табигате, анда яшәгән җир кешеләре.

Менә шуларны шагыйрь, тормыш дөреслегенә хилафлык китермичә, солдатларча кырыс һәм төгәл детальләр аша, табигый тонда сурәтләргә омтыла. Аның шигырьләре, форма, ритм җәһәтеннән кайчак кытыршырак тоелсалар да, укучыны үзенчәлекле шигъри образлары һәм фикер-хисләренең ихласлыгы һәм табигыйлеге белән җәлеп итәләр.

Х.Камал — күп кенә поэмалар авторы. Сугыш темасына багышланган «Яну» (1958), яшьләр арасындагы мәхәббәт, гаилә кору кебек әхлак мәсьәләләрен күтәргән «Мәхәббәт хакы» (1961), узган гасырның алтмышынчы-җитмешенче елларында шагыйрьнең туган ягында барган икътисади һәм көнкүрештәге үзгәрешләрне хатирәләр һәм фәлсәфи уйланулар аша сурәтләгән «Туган җирдә» (1964), «Әнкәй истәлеге» (1964), тарихи-фәлсәфи пландагы «Көндәлектәге язулар» (1966), Кама автомобиль заводы төзелешендәге эшче яшьләр тормышыннан алып язылган «Яшьлек елмаюы» (1973) кебек поэмалар шагыйрьнең иҗатында күренекле урын тоталар.

Узган гасырның җитмешенче елларыннан башлап Хисам Камал проза жанрында активрак иҗат итә. Үзе яшәгән чорның бәла-казаларга мул чынбарлыгын, фронттагы юеш-салкын окопларда һәм тылдагы хезмәт вахталарында афәтле сугыш фаҗигаләре чорын зур түземлелек белән кичергән гади кешеләрнең — үз замандашларының гыйбрәтле язмышларын күпертмичә-бизәмичә, бөтен кырыс хакыйкатенә тугрылык белән сурәтләп биргән «Һәркемнең гомере бер генә» (1975), «Безне өйдә көтәләр» (1982), «Үлгәннән соң яздым» (1989), «Түләнмәгән күз яше» (1995) романнары, «Бердәнбер ул» (1982) кебек повесть һәм дистәләрчә хикәяләр әдипнең проза жанрындагы зур иҗади уңышларына мисал була ала.

Гомумән, 1955—2000 еллар арасында әдипнең татарча оригиналында һәм рус теленә тәрҗемәдә барлыгы егерме сигез китабы дөнья күрә. Шул арның егерме бере — шигырь җыентыклары, җидесе — проза әсәрләре, шул җөмләдән биш роман. 2004 елгы «Казан утлары» журналының 10, 11, 12 нче саннарында «Үксезләр» исемендә әдипнең чираттагы яңа романы басылып чыкты. «Һәркемнең гомере бер генә» һәм «Безне өйдә көтәләр» романнары өчен Х.Камал 1986 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. 2001 елда исә, татар әдәбиятын үстерүдә ирешкән зур казанышларын искә алып, аңа Татарстан Республикасының халык язучысы дигән шәрәфле исем бирелде. Хисам Камал — 1958 елдан СССР һәм Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.



Кави Латыйп
(1927)

Кави Латыйп (Кави Таһир улы Латыйпов) 1927 елның 1 маенда Чувашстан АССРның Батыр районы Кызыл Чишмә авылында крестьян гаиләсендә туган. 1943 елда урта мәктәпне тәмамлагач, берникадәр вакыт шул ук районның Татар Тимәше дигән авылда балалар укыта.

1944 елның көзендә Совет Армиясенә алына, Бөек Ватан сугышында катнаша, «Сугышчан хезмәтләре өчен» дигән һәм башка медальләр белән бүләкләнә. Сугыштан соң Хәрби-политик училище тәмамлап, 1955 елның октябренә кадәр офицер булып хезмәт итә. Армиядән демобилизацияләнеп кайткач, 1955—1959 еллар арасында башта ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында инструктор, аннары Татарстан Мәгариф министрлыгында инспектор булып эшли. 1959—1962 елларда К. Латыйп Казан телестудиясендә, ә аннаң соң 1978 елга кадәр күп тиражлы газетада редактор вазифаларың башкара. 1978—1982 елларда ул СССР Педагогика фәннәре академиясенең Казан профтехпедагогика фәнни-тикшеренү институтында өлкән гыйльми сотрудник булып эшли. 1982 елның көзеннән — профессионал-язучы хезмәтендә.

К. Латыйпның «Солдат эзләре» исемле беренче шигырьләр китабы 1960 елда басылып чыга. Поэзиядән тыш, әдәбиятның башка жанрларында да актив эшли: балалар һәм яшүсмерләр өчен хикәяләр, повестьлар, очерк, документаль проза әсәрләре яза. Чуваш халкының батыр улы Андриан Николаев турындагы «Йолдыз тапкан егет» повесте, «Мизгел» исемле хикәяләр җыентыгы, гражданнар сугышы чорының легендар герое В. Чапаевның балалык елларына багышланган «Бәләкәй Чапай» повесте укучылар тарафыннан җылы каршы алынды. Поэзия өлкәсендә дә автор китаптан китапка үсә бара. Соңгы елларда язылган шигырьләре образлы теле, тормышчан төгәл детальләре, заманча яңгырашлы фәлсәфи фикерләре белән игътибарны җәлеп итә.



К. Латыйпның шигырьләре һәм аерым проза әсәрләре рус һәм чуваш телләренә дә тәрҗемә ителгән.



Мөнир Мазунов

(1918 – 1987)



Мөнир Хәсән улы Мазунов 1918 елның 1 апрелендә хәзерге Пенза өлкәсенең Лопатин районы Иске Карлыган авылында туган. Авылда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, 1935—1938 елларда Әстерхан педагогия техникумында белем ала, аннан бер ел Удмурт АССРның башкаласы Ижевск шәһәрендәге урта мәктәпләрнең берсендә татар теле һәм әдәбияты укыта.

1939 елда Совет Армиясенә алынып, Бөек Ватан сугышы елларында Ерак Көнчыгышта хезмәт итә, 1945 елның җәендә, «Тревога» исемле фронт газетасының алгы сызыктагы корреспонденты буларак, япон гаскәрләренә каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша.
1946 елда М. Мазунов Казанга килә һәм 1949 елга кадәр Татарстан радиокомитетында редактор булып эшли. Бер үк вакытта ул Казан педагогия институтының читтән торып уку бүлегендә белем ала.

1949—1953 елларда М.Мазуноз совет гаскәрләренең Төньяк группасы составында Польшада чыга торган газета редакциясендә өлкән әдәби сотрудник булып эшли. М. Мазунов сугышчан хезмәтләре өчен сигез тапкыр хөкүмәт бүләкләренә лаек була. Армиядән кайтканнан соң, Татарстан радиокомитетында (1953—1959) редактор һәм радиокомитет начальнигы урынбасары, аннары начальнигы, Татарстан китап нәшриятында (1960—1963) өлкән редактор, республика газета-журналлар нәшриятында (19Б4—1967) тәрҗемәче һәм 1967 елдан 1971 елга кадәр рус һәм татар телләрендә чыга торган «Татарчаң кооператоры» газетасының җаваплы редакторы булып эшли. 1971 елдан бирле фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

М.Мазуновның беренче шигъри тәҗрибәләре сугышка кадәрге елларда Әстерхан һәм Ижевск шәһәрләрендә чыга торган татарча газеталарда басыла. Бөек Ватан сугышы чорында фронт газеталарында, ә 1944—1945 еллардан башлап Татарстан республика көндәлек матбугатында, альманах һәм җыентыкларда М. Мазуновның исеме бик еш күренә башлый. 1948 елда шагыйрьнең беренче мөстәкыйль китабы басылып чыга ("Елда уникe ай"). Хәзерге көндә ул — ике дистәгә якын китап авторы. Аларның күбесе балаларга багышланганган. Мазуновның шагыйрь буларак иҗади йөзе нәниләр өчен язган шиьрләрендә һәм бигрәк тә җырларында чагыла. Аның «Туган як» (М.Мозаффаров), «Язгы хисләр» (Р.Яхин музыкасы), «Яшьләр (Ә.Бакиров музыкасы), лирик характердагы «Әниемнең җылы кочагы» (Ә.Бакиров музыкасы) кебек җырлары, халык арасында популярлык казанып, үзешчән һәм профессиональ башкаручылар репертуарыннан төшмичә, озак еллар буе даими җырланып килә.

М.Мазунов шигъри тәрҗемә өлкәсендә дә каләм тибрәтә. Ул Дж.Родари, М.Нагнибеда, Н. Хикмәт, С.Маршак, П.Хузангай һәм башка чит милләт әдипләренең аерым әсәрләрен, Н. Некрасовның «Суык борыны кызыл кукк» («Мороз, Красный нос») һәм А.Прокофьевның



Мәхмүд Максуд

(1990 – 1962)

Мәхмүд Гыйсаметдин улы Максудов 1900 елның 15 гыйнварында Татарстанның Сабарайоны Югары Кибәхуҗа авылында мулла гаиләсендә туа. Биш-алты яшендә әти-әнисеннән хәреф таныргa өйрәнә һәм кечкенәдән үк китап укырга һәвәс булып үсә. М.Максуд Кышкар мәдрәсәсендә, Арчадагы ике класслы рус-татар мәктәбендә һәм Малмыж шәһәрендәге Югары башлангыч училище дип йөртелгән уку йортында белем ала. Мәктәп елларында татар һәм рус язучыларының әсәрләре белән таныша, үзе дә каләм тибрәтә башлый: беренче өйрәнчек шигырьләрен, хикәяләрен яза.

1921 елның гыйнварында М.Максуд Мәскәүгә чакыртып алына һәм “Яшь эшче”, “Коммунист” газеталары редакцияләрендә, Мәскәү нәшриятларында эшли. Шул ук чорда әдип, төп хезмәтеннән аерылмыйча укып, башта Көнчыгыш хезмәт ияләре коммунистик университетының тарих-табигать фәннәре бүлеген, аннары Мәскәү дәүләт университетының этнология факультетында әдәбият бүлеген тәмамлый. 1934 елдан бирле профессионал язучы.

Бөек Ватан сугышының беренче көненнән алып, М.Максуд Совет Армиясе сафларында политрук, баталон комиссары, политбүлек агитаторы, фронт газетасының редактор урынбасары булып хезмәт итә. Сугыштан соңгы елларда М. Максуд байтак кына оригинал әсәрләр: очерклар, шигырьләр, тәнкыйть мәкаләләрен яза.



М.Максуд – бөтен иҗат гомере буена тәрҗемә өлкәсендә эзлекле рәвештә эшләп килгән язучыларның берсе. Ул классик әдәбият җәүһәрләреннән А.С.Пушкин, Н.А. Некрасов, Л.Н.Толстой, А.М.Горький, шулай ук Низами, Гете, Абай һәм башка бик күп язучыларның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.



# Шәйхи Маннур

(1905 – 1980)

Шагыйрь һәм прозаик Шәйхи Маннур (Шәйхелислам Фәрхулла улы Маннуров) 1905 елның 15 гыйнварында элекке Казан губернасы Мамадыш өязе (хәзер Татарстанның Мамадыш районы) Тулбай авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылында һәм күрше авылдагы мәдрәсәдә ала. Аннары күрше Шәмәк авылында ачылган мәктәптә һәм Мамадыш шәһәрендәге педагогия курсларында укый.

1921 елда аның әтисе гаиләсе белән Кузбасстагы Анжерка-Судженка шахталарына күчеп китә. Шунда Ш.Маннурның хезмәт юлы башлана.
Ул 1923 елда Свердловскидагы бер еллык совет-партия мәктәбендә укый, биредә чынлап торып әдәби иҗат эшенә керешә. Урал төбәге татарлары өчен чыгарылган газета-журнал битләрендә, соңга таба Казан һәм Мәскәү татар көндәлек матбугатында аның күп кенә шигырьләре һәм әдәби язмалары дөнья күрә.

1924 елдан Ш.Маннур өч елга якын Себернең төрле төбәкләрендә яши һәм эшли. 1927-1929 елларда армия сафларында хезмәт итә. Армиядән кайткач, Донбасс якларына китеп, металлургия заводында – эшче-прокатчы, шахтерлар мәктәбендә – укытучы-ликбезчы һәм ДнепроГЭС төзелешендә бетончы хезмәтендә була. Бу елларда Ш. Маннурның иҗат эшчәнлеге аеруча активлаша. Ул «Колчеданлы таулар өстендә» (1929), «Чуен ташкыннар» («Чугунные потоки») (1930), «Бетончылар җыры» (1932) исемле беренче поэмаларын һәм күп санлы лирик шигырьләрен яза. Аның бер-бер артлы шигырь җыентыклары басылып чыга. Мәскәүдә, «Эшче» газетасы редакциясендә эшләп алгач, Ш. Маннур Казанга килә һәм 1933-1937 елларда педагогия институтында укый. 1934 елда аның атаклы «Гайҗан бабай» һәм тагын бер елдан «Меңнән бер кичә» поэмалары языла.



Бөек Ватан сугышы башлангач, шагыйрь үзе теләп фронтка китә, хәрби газеталарда эшләп, күп санлы хәбәрләр, очерклар, шигырьләр бастыра. Сугыштан соң, 1946-1948 елларда Ш.Маннур Казанда Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының әдәби бүлек мөдире булып эшли, ә 1949 елдан профессиональ язучылык хезмәтенә күчә.

1960-70 нче еллар әдәби хәрәкәтендә Ш.Маннур прозаик буларак катнаша. Ул иҗат итк
проза әсәрләре арасында иң күренеклесе – «Муса» романы (1959-1964). «Агымсуларга

Ш.Маннурның әдәби мирасы зур һәм күпкырлы. Үзе исән чагында аның дүрт дистәгә якын китабы дөнья күрә. Алар арасында махсус балаларга адресланганнары да бар. Ул шулай ук әдәби тәнкыйть, публицистика, очерк һәм әдәби тәрҗемә жанрларында да нәтиҗәле эшли.

Ш.Маннур 1980 елның 10 июнендә Казанда вафат була һәм үзенең язма васыяте буенча туган авылы Тулбай авылы зиратына җирләнә.

Ш.Маннур 1957 елда туган авылында үз акчасына китапханә салдыра һәм 100 данә китап бүләк итеп бирә. 1980 елда киатпханәгә Шәйхи Маннур исеме бирелә. 1995 елда аңа Татарстан берләштерелгән дәүләт музееның филиалы статусы бирелә һәм музей-китапханә исемен йөртә башлый.

1981 елдан бирле һәр елның 15 гыйнварында, язучының туган көнендә, туган авылында Шәйхи Маннур исемендәге премия бирелеп килә.

**Балама**

*Ерак юллар буйлап үткән чакта,*
*Кошлар тавышын тыңлап барсам да;*
*Бөреләнеп яңа чәчәк аткан*
*Яшь гөлләрне өзеп алсам да, -*
*Искә төшә кинәт бәгърем-балам,*
*Күз алдыма килә елмаеп.*
*Сагынып уйлап, ялгыз җырлап алам,*
*Чәчәкләргә карап моңаеп.*
*Нишләп йөри икән түгәрәгем,*
*Ниләр сөйли икән иртәсен.*
*“Кайтамы, - дип, - әтием инде бүген?”*
*Кочып сорый микән әнкәсен.*
*Мин кайтырмын, балам, тиздән-тиздән,*
*Син көтеп тор сагынып әткәңне, -*
*Сөрик кенә изге җиребездән*
*Каһәр суккан шашакан этләрне.*
*Мин сугышам синең өчен,*
*Синең бәхетең өчен сугышам.*
*Син уйный тор, бәгърем, иртә-кичен,*
*Мин кайтырмын тиздә, сау булсам.*
*Туган илдән куып дошман көчен,*
*Мин кайтырмын, гөлем, сау булсам,*
*Син корал тот һәм ал әткәң үчен,*
*Мин сугышта әгәр егылсам.*
*июль, 1942.*



Зыя Мансур

(1916 – 1965)

Зыя Мансур улы Мансуров 1916 елның 17 декабрендә хәзерге Башкортстан АССРның Дүртөйле районы Җитембәк авылында игенче гаиләсендә туа. 1937 елда урта мәктәпне тәмамлагач, Дүртөйле район газетасында башта корректор, соңга таба әдәби сотрудник булып эшли.

1939 елда гаскәри хезмәткә алына һәм, Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк хәрби-пехота мәктәбенә җибәрелеп, 1941 елның ахырында аны тәмамлап чыга, аннары 1942 елның башыннан сугыш беткәнчегә хәтле хәрәкәттәге армиядә хезмәт итә, авыр сугышларда катнаша, яралана, фронтта күрсәткән батырлыклары өчен Икенче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр белән бүләкләнә. Армиядән демобилизациялөнгәч, З.Мансур туган якларына кайта һәм 1946—-1949 еллар арасында Дүртөйле район үзәгендә радиотапшырулар дикторы, аннары Илеш районы Культура йортының директоры булып эшли. 1949 елның җәендә Казанга килеп, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге университетның филология факультетына укырга керә, ләкин ике елдан сәламәтлеге начараю аркасында укуын ташларга мәҗбүр була һәм Татарстан радиокоми-тетында әдәби тапшырулар редакторы булып эшли башлый. 1953—1955 елларда З.Мансур «Чаян» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр вазифасында, ә 1956 елдан фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Зыя Мансур поэзиягә давыллы сугыш елларында килә. Аның Ватан азатлыгы өчен изге көрәшкә күтәрелгән совет солдатының патриот хисләрен, кичерешләрен чагылдырган беренче лирик шигырьләре утлы-ялкынлы фронт тормышы шартларында —окопларда һәм солдат землянкаларында язылалар. Инде сугыш афәте бетеп, тыныч тормышка кайткач, шагыйрьнең иҗат омтылышлары өчен киң мәйдан ачыла. Ул дәртләнеп-ялкынланып иҗат эшенә чума. 1950 елда, университетта укыган чагында, аның «Язгы ташкыннар» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә, аннары ул ел аралаш диярлек яңа китап бирә бара. Гомумән, үзе исән чагында З.Мансурның 10 җыентыгы басылып чыга.



Юмор-сатира — З.Мансур иҗатының шулай ук көчле якларыннан берсе. Тормышның ямен китәрүче аерым типлар: карьеристлар, бюрократлар, исерекләр, халыкара сугыш чукмарлары, буржуаз журналистлар һ. б. шагыйрьнең сатирик әсәрләренә төп материал хезмәтен үтиләр. Аларны тәнкыйтьләү өчен автор сатира жанрының төрле формаларына мөрәҗәгать итә. З.Мансур балалар өчен дә иҗат иткән шагыйрь. Аның мәктәп тормышы, табигать күренешләре турындагы шигырьләрен, «Омтылу» (1951), «Озын колак баласы Елак-Мылак» (1955) кебек поэма-әкиятләрен балалар яратып укыйлар. Зыя Мансур 1965 елның 11 ноябрендә Казанда вафат булды.



# Шәрәф Мөдәррис
(1919 – 1963)



Шәрәф Хасиятулла улы Мөдәррисов 1919 елның 1 ноябрендә хәзерге Татарстан АССРның Чүпрәле районы Түбән Каракитә авылында крестьян гаиләсендә туган. Үз авылында башлангыч һәм күрше Мунчәли авылындагы җиделлык мәктәпне тәмамлагач, 1935 елда Казанга килә Һәм педагогия институты каршындагы рабфакка укырга керә, аннары ике еллык укытучылар институтында укый. Ш.Мөдәррис студентлык чорында аеруча дәртләнеп иҗат итә. 1937 елда ук инде унсигез яшьлек егетнең «Үскәндә» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Шагыйрьнең әдәби тәрҗемә өлкәсендәге беренче тәҗрибәләре дә шушы чорда башлана.

1941 елда аның тәрҗемәсендә чуваш әдәбияты классигы Константин Ивановның атаклы «Нарспи» поэмасы басылып чыга. Поэманың турыдан-туры оригиналдан тәрҗемә ителүе ул заман тәнкыйтендә аеруча уңай күренеш итеп бәяләнә. Берникадәр вакыт республика яшьләр газетасы «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») редакциясендә эшләгәннән соң, Ш. Мөдәррис 1941 елның язында Кызыл Армия сафына алына. фашист Германиясенең мәкерле һөҗүмен ул кулына корал тотып Белоруссия чигендә каршылый. 1941 елның җәендә Смоленск өлкәсендә барган канлы сугышларның берсендә Ш. Мөдәррис яраланып, контузия ала һәм Мәскәү госпиталенә озатыла, аннан сәламәтлеген ныгыту өчен Казанга һәм туган авылына кайта. 1942 елның җәендә, сәламәтлеге яхшыргач, ул яңадан сугышка китә, минометчы-солдат булып Төньяк-Көнбатыш фронтында сугыша, аннан шул ук фронтта татар телендә чыга торган «Ватан өчен» исемле газета редакциясендә хәрби корреспондент булып хезмәт итә. 1944—1945 елларда Ш. Мөдәррис бу эшен «Җиңү байрагы», «Фронт хакыйкате» исемле фронт газеталарында дәвам иттерә. Корреспондент буларак ул атналар буе алгы сызыкта сугышчылар арасында йөри, фронт тормышын үз күзе белән күреп-өйрәнеп, совет сугышчыларының героик көрәшен күп санлы мәкаләләрендә, очеркларында гәүдәләндерә.

Сугыш чынбарлыгыннан алынган конкрет вакыйгалар, эш-гамәлләр Шәрәф Мөдәрриснең бу чор поэтик иҗатының да төп эчтәлеген тәшкил итә. Лирикасында, «Тупчы Ваһап» (1943) исемле күләмле эпик поэмасында шагыйрь нәкъ менә шул үзе аралашып яшәгән гади совет кешеләренең хисләрен, сугыштагы батырлыкларын, аларның гуманизмын, фашизмга үтергеч нәфрәтләрен тасвирлый.

1946 елның язында армиядән кайткач, Шәрәф Мөдәррис «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан») һәм «Яшь сталинчы» газетасы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1956 елда ул, читтән торып укып, М. Горький исемендәге әдәбият институтын тәмамлый. Сугыштан соңгы елларда Ш. Мөдәрриснең әдәби иҗаты, жанр һәм эчтәлек ягыннан төрлеләнеп, тагы да үсеп-җәелеп китә. Ул зур күләмле поэмалар, шигъри повестьлар яза, лирик һәм публицистик шигырьләр, юмор-сатира әсәрләре, хикәяләр һәм памфлетлар иҗат итә, матбугатта халыкара темаларга үткен эчтәлекле публицистик мәкаләләр бастыра. Татар поэзиясендә беренчеләрдән булып, ул сонет жанрына юл ача, аның матур үрнәкләрен язып күрсәтә. Шагыйрь тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. Аның инглиз теленнән тәрҗемә иткән Шекспир сонетлары, «Король Ричард III» трагедиясе, Байрон, Шелли шигырьләре, немецчадан Гейне шигырьләреннән үрнәкләр, Пушкин, Некрасов, Шевченко кебек бөек шагыйрьләрнең аерым әсәрләре — болар һәммәсе татар тәрҗемә әдәбиятының шул еллардагы зур уңышы итеп каралырга хаклы. Ш. Мөдәррис шигъри талантының ачылып җиткән чорында, 1963 елның 28 апрелендә вафат булды.

### ***Таныш кунак***

*Көчле сугыш. Дөнья шаулап тора,*
*Әйтерсең лә ташый лавалар...*
*...Чыршылыкта дулап кайнап тора*
*Аккош төсле нәфис самовар!*
*Көчле сугыш. Урман выжлап тора,*
*Тузан-төтен каплый күземне...*
*...Ул бит шунда сузып җырлап тора,*
*Күрче, иптәш, гаҗәп түгелме?!*
*Без бу җирдә, Ватан каршысында,*
*Башкарабыз гадел бурычны.*
*Ул бәйли күк монда, канлы кырда,*
*Туган өй һәм көчле сугышны!*
*Хәтерләдем шунда узган көнем,*
*Мескенкәем әнкәм-җанымны;*
*Сеңелләрем белән уйнап-көлеп,*
*Кичке чәйне эчкән чагымны...*
*Сайра шулай булар бөрки-бөрки,*
*Җырла, туган, җырчы шикелле!*
*Син ич монда, дустым, гөрли-гөрли*
*Кайнатасың минем хисемне!*
*Синең җырың сүнеп, сулып калса,*
*Сугышчылар күмер салалар.*
*Син кунак ич безгә сугышларда,*
*Гөрли-гөрли кайна, самовар!*

*1942*



Кави Нәҗми
(1905 – 1957)

1901 елның 15 декабре. Горький өлкәсе Петрякс районы Красный Остров авылында бер ир бала дөньяга килә. Һибәт абзый матур хыялларга чума. Ир малай бит, бер имана җир арта дигән сүз. Ләкин яңа туган балага тиешле җир генә ул вакыттагы авыр тормышны җиңеләйтә алмый. Һибәт абзый, гаиләсен алып, чит җирләргә чыгып китәргә мәҗбүр була. Алар Актүбә шәһәрендә яши башлыйлар.
Монда Кави 6 еллык рус-татар мәктәбенә укырга йөри. Җәйге айларда тамак ялына төрле эшләрдә эшли.

Кави Нәҗми яшьтән үк Г. Тукай, М. Гафури, Ш. Камал кебек күренекле язучыларның әсәрләре белән таныша. Шулар йогынтысында 1912 елны «Көз» исемле беренче шигырен яза, рус шагыйре А. О. Кольцовның «Урман» шигырен татарчага тәрҗемә итә. 1919 ел башларында Кави Сембердәге педагогия курсларына укырга керә. Курсларны тәмамлагач, матбугат эшләрендә катнаша башлый. Тиздән гражданнар сугышына китә һәм ак интервентларга каршы көрәшә.

1923 елда Мәскәү Югары хәрби педагогия институтын тәмамлый. Казандагы татар-башкорт хәрби мәктәбендә сәяси фәннәр укыта, соңрак комиссар була. 1927 елда Казанда чыга торган «Кызылармеец» газетасында редактор булып эшли башлый.
Бу елларда язучы күп кенә хикәяләр, повестьлар яза. Аның әсәрләре Октябрь борылышына кадәрге тормышны һәм революцион хәрәкәтне («Миңлебикә кодагыйның кайгысы», «Кайтты»), гражданнар сугышы чоры вакыйгаларын («Чыныгу», «Иң соңгысы», «Шобага», «Яр буенда учаклар»), крестьяннарның колхозларга берләшүен («Якты сукмак», «Кояшлы яңгыр») чагылдыралар.
1932 елда Кави Нәҗми Татарстан Язучылар берлеген оештыру комитетына сайлана. «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналы редакторы булып эшли. Бөтенсоюз совет язучыларының Беренче съездында катнаша һәм татар матур әдәбияты турында доклад ясый. Съездда аны СССР Язучылар берлеге идарәсенә әгъза итеп сайлыйлар.



1941—1945 елларда ул Татарстан радиокомитетында эшли. Бөтен иҗат сәләтен фашизмны җиңү эшенә багышлый. 1949 елда Кави Нәҗми Казан эшчеләренең революцион көрәшкә катнашуларын сурәтләгән «Язгы җилләр» романын бастырып чыгара. Бу китап, шул чор татар прозасының күренекле әсәрләреннән берсе буларак, Дәүләт премиясенә лаек була.

К. Нәҗми — гомере буе язучылык хезмәтен иҗтимагый-сәяси һәм дәүләт эшләре белән бергә бәйләп барган әдип. Шушы хезмәтләре өчен хөкүмәтебез аны орден һәм медальләр белән бүләкләде.



Мостафа Ногман
(1912 – 1976)

Мостафа Ногман улы Ногманов 1912 елның 22 декабрендә хәзерге Татарстан АССРның Арча районы Кызыл Яр авылында туа. 1931 елда Казан педагогия техникумын тәмамлый, аннары берничә ел Татарстан һәм Таҗикстан мәктәпләрендә укытучы, 1935—1937 елларда Дүшәмбе шәһәрендә Хәрби трибуналда секретарь булып эшли, 1937—1941 елларда Дүшәмбе дәүләт педагогия институтының кичке бүлегендә укый.

Бөек Ватан сугышы чорында юстиция өлкән лейтенанты сыйфатында Совет Армиясендә хезмәт итә. 1945 елда армиядән демобилизацияләшкәч, М.Ногман Казанга килә һәм ике елга якын «Пионерская правда» газетасының Татарстандагы үз хәбәрчесе булып эшли. 1947—1951 елларда М. Ногман — Мәскәү Көнчыгышны өйрәнү институты студенты. Институтны фарсы, төрек телләре белгечлеге буенча уңышлы тәмамлагач, ул 1953—1957 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында татар теле буенча аспирантурада укый. Шундагы гыйльми эзләнүләрен гомумиләштереп диссертация яклый һәм филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала.

1957—1959 елларда М. Ногман Казан дәүләт университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә Көнчыгыш кулъязмаларын барлау-тикшерү, тасвирламаларын төзү буенча гыйльми эш алып бара. Гомеренең соңгы уналты елында (1960—1976) исә ул Казан университетының тарих-филология факультетында студентларга фарсы һәм борынгы татар теле укытты.



Тел белеме өлкәсендә әһәмиятле гыйльми тикшеренүләр алып бару белән бергә, М.Ногман поэзия жанрында актив эшләде һәм үзенчәлекле эз калдырды. Аның беренче шигырьләре Бөек Ватан сугышы чорында язылалар һәм басылып чыгалар («Давыллы еллар лирикасы» җыентыгы, 1944). Сугыштан соңгы елларда ул шигъриятта үз юлын табарга омтыла: лирик һәм публицистик шигырьләр, тарихи һәм революцион үткәнне, Бөек Ватан сугышы героикасын тасвирлаган поэмалар иҗат итә («Җир турында җыр», 1958; «Кокушкино таңнары», 1962; «Үлмәс чәчәк легендасы», 1967—1968 һ. б.). Ахырда, җыр жанрына тукталып, шигъри талантын аеруча шушы өлкәдә ныграк ачуга ирешә. Аның «Карлыгандай кара күзләреңә» (1945) исемле беренче җыры ук (З.Исмәгыйлев музыкасы) халыкта киң популярлык казана. Аннан бер-бер артлы башка җырлар языла. Илленче еллардан башлап, композиторлар тарафыннан шагыйрьнең җиде дистәгә якын шигъри әсәре музыкага салына. Боларның шактый зур өлеше күренекле композитор Рөстәм Яхин белән иҗади дуслыкта туган. Шагыйрьнең аерым шигырьләренә шулай ук А. Ключарев («Сәлам сиңа, Куба», «Яшь йөрәкләр җыры», «Ак мәрмәр колонналар»), М. Мозаффаров («Кырлар яңарганда»), А. Монасыйпов («Бер, егет кайтты фронттан»), Ф. Әхмәтов («Таң йолдызы», «Сибелә, сибелә алма чәчәкләре») һәм башка профессиональ һәм үзешчән композиторлар да музыка язганнар.
Шагыйрьнең сайланма шигырьләре, поэмалары, җырлары һәм тәрҗемәләре 1982 елда басылып чыккан «Акчарлаклар оча Иделдә» исемле җыентыгында урын алган.
М. Ногман 1976 елның 4 сентябрендә Казанда вафат булды.



## Зәки Нури
(1921 – 1994)

Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдинов 1921 елның 24 декабрендә Татарстан АССРның Чүпрәле районы Татар Төкесе авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туган. Җидееллык колхоз яшьләре мәктәбен (ШКМ) тәмамлаганнан соң, 1934—1937 һәм 1940—1941 елларда Татарстанның хәзерге Кукмара районындагы Лубян урман техникумында белем ала, 1938—1940 еллар арасында Ерак Көнчыгыштагы Николаевск-на-Амуре шәһәрендә диңгез порты төзелешендә һәм Чувашстанның Шемурша урман хуҗалыгында үз белгечлеге буенча хезмәт чыныгуы уза. 1941 елның маенда З.Нури хәрби хезмәткә алына һәм, илнең Көнбатыш чигенә җибәрелеп, артиллерист сыйфатында, гитлерчылар һөҗүменең беренче көннәреннән үк фашист илбасарларына каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1941 елның августында, полкташлары белән бергә чолганышка эләгеп, ул дошман тылында кала һәм, партизаннар отрядына кушылып, 1942 елның мартыннан 1944 елның августына кадәр атаклы Константин Заслонов җитәкчелегендәге белорус партизаннары берләшмәсендә башта дошман объектларын шартлатучы-диверсант, соңыннан «Җиңү» («Победа») исемле разведка отряды начальнигы булып хезмәт итә. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен З. Нури Ватан сугышы ордены (1948), «Ватан сугышы партизанына» медале (1944) һәм башка медальләр белән бүләкләнә.

Белоруссия җирләре фашист илбасарларыннан азат ителгәннән соң, 1944 елның августыннан 1946 елның көзенә кадәр, З.Нури хезмәт ияләре депутатларының Орша шәһәре Советында башкарма комитет председателе урынбасары вазифасын башкара һәм шәһәрне сугыш хәрабәләреннән арындыру, торгызу буенча зур оештыру эшләре алып бара. Соңыннан, 1975 елда, фашист Германиясен җиңүгә утыз ел тулу көннәрендә, хезмәт ияләре депутатларының Орша шәһәр советы башкарма комитеты карары белән, Зәки Нурига Орша шәһәренең Почетлы гражданы дигән мактаулы исем бирелә.



1946 елда З.Нури туган якларына кайта һәм 1946—1949 еллар дәвамында башта Буа урман базасы, аннары Тархан леспромхозы директоры булып эшли. 1949 елның ахырында З.Нури Казанга килә һәм «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасы редакторы урынбасары итеп билгеләнә. 1951—1955 елларда Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире, аннары берникадәр вакыт Татарстан Язучылар I союзында әдәби консультант һәм Идарәнең җаваплы секретаре хезмәтен Үти. 1957 елда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби Курсларны тәмамлап кайтканнан соң, З. Нури алты елга якын (1957—1963) Татарстан Язучылар союзының җаваплы секретаре, 1964—1971 елларда «Казан утлары» журналының баш редакторы, ә 1971 елның язынннан алып 1974 елның маена кадәр Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе булып эшли. Бер үк вакытта (1970—1975) ул СССР Язучылар союзы секретарьларыннан берсе итеп сайлана

Зәки Нуриның беренче шигъри тәҗрибәләре сугыш алды елларында көндәлек матбугатта һәм күмәк җыентыкларда күренә башлый. Шулай да шагыйрь буларак ул Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы чорда формалаша. 1945 елда сугышчы-партизанның ватандарлык, дуслык-туганлык хисләре һәм фашизмга карата нәфрәт белән сугарылган беренче җыентыгы («Шигырьләр») басылып чыга. Гомумән, Ватан сугышы темасы, партизан лирикасы шагыйрьнең бөтен иҗаты буенча үзенчәлекле бер агым булып дәвам итә. Лирик шигырьләрдән һәм «Дан юлы», «Урманда утлар» кебек поэмаларыннан тыш, әдипнең сугыш темасына алтмышынчы елларда язылган «Үлгәннәр дә үч алды» исемле проза әсәре дә бар.

Зәки Нуриның сугыштан соңгы поэтик иҗат эшчәнлеге жанр ягыннан нигездә өч тармакта бара: публицистик лирика, балалар поэзиясе һәм юмор-сатира әсәрләре. Шагыйрьнең лирикасы бигрәк тә гражданлык, интернационализм мотивлары, публицистик-политик рухы белән аерылып тора. Ул, иҗатчы буларак, ил тормышындагы мөһим вакыйгаларга мөнәсәбәтен белдереп барырга тырыша. Туган илне сөю, аның тарихи казанышлары, көндәлек уңышлары белән горурлану — З. Нури поэзиясенең төп идея эчтәлеген тәшкил итә. Шушы ук патриотик хисләр һәм сыйфатлар аның күп санлы юмор-сатира әсәрләренең, балалар өчен язган шигырьләренең дә пафосын билгели.

З.Нури — әдәбиятта актив эшләүче авторларның берсе. 1945—1983 еллар арасында аның татар телендә — утыз алты, рус теленә тәрҗемәдә — унҗиде, башка халыклар теленә тәрҗемәдә алты — барлыгы илле тугыз исемдә аерым китабы басылып чыга. Шагыйрьнең иҗат йөзен билгели торган шигырь һәм поэмалары 1980 елда Татарстан китап нәшриятында «Шигырь китапханәсе» сериясендә дөнья күргән «Күңел яктысы» исемле күләмле җыентыгында урын алган.

З.Нури шигъри тәрҗемә өлкәсендә нәтиҗәле эшли. Ул — татар телендә алты томлы Ленининиана чыгаруны оештыручы һәм тәрҗемә итүчеләрнең берсе. Күренекле рус шагыйрьләре А. Твардовскиййың «Дом у дороги» («Юл буендагы йорт», 1951), С.Щипачевның «Дом в Шушенском» («Шушен-скоедагы өй», 1953), В. Саяновның «Ленин в Горках» («Ленин Горкида», 1954) исемле поэмаларын, украин шагыйре П. Воронькоғың балалар өчен язган шигырьләрен («Синең китабың», 1955), кыргыз совет шагыйре К. Җу-нусов, белорус поэзиясе классигы Я- Колаеның поэтик әсәрләрен татар укучылары З. Нури тәрҗемәсендә укыйлар. Ул шулай ук, үзе төзеп һәм татарчага тәрҗемә итеп, аерым серия рәвешендә, 1967—1975 еллар арасында әзәрбайҗан, белорус, казакъ, үзбәк, төрекмән, кыргыз, таҗик, украин, рус, латыш, литва, эстон, әрмән һәм грузин совет поэзиясенең иң яхшы үрнәкләре тупланган махсус җыентыклар бастырып чыгарды. Дөнья халыклары һәм илебездәге кардәш халыкларның фольклор әсәрләрен (мәзәкләр, мәкаль-әй-темнәр һ. б.) үз эченә алган «Күңелле китап» (1969, 1979), «Алтын хәзинә» (1973) исемле күләмле җыентыклар да әдипнең тәрҗемә өлкәсендәге күпкырлы эшчәнлеге турында сөйли.

З.Нури — актив җәмәгать эшлеклесе. Ул өч тапкыр (1961, 1968, 1979) халык депутатларының Казан шәһәр советы депутаты, ике тапкыр (1967, 1971) Татарстан АССР Верховный Советы депутаты, өч тапкыр (1961, 1964, 1974) КПССның Казан шәһәр комитеты Пленумы члены итеп сайланды, төрле елларда СССР Язучылар союзының идарә члены (1975—1980) һәм ревизия комиссиясе члены (1961—1971), РСФСР Язучылар союзы идарәсе члены (1970—1975) вазифаларын башкарды. 1975 елдан бирле ул — Татарстан Язучылар союзы идарәсе члены; 1971—1974 елларда Идарәнең председателе булып эшләде.

Әдәбият өлкәсендәге һәм җәмәгать тормышындагы хезмәтләре өчен З.Нури 1971 елда «Почет Билгесе», ә 1981 елда Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнде.



## Сөббух Рәфыйков
(1913 – 1971)

Сөббух Һади улы Рәфыйков 1913 елның 15 июлендә хәзерге Татарстан АССРның Сарман районы Нөркәй авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1925— 1930 елларда башта Чаллыда һәм Алабугада тугыз еллык мәктәптә, аннары Казанда югары уку йортына хәзерләү курсларында укый.

1931 елдан башлап ул журналистлык эшендә: республика «Колхоз гәзите» редакциясендә әдәби хезмәткәр (1931 —1932), Сарман районында чыга торган «Комбайн» газетасында җаваплы редактор урынбасары (1932—1934), республика комсомол газетасы «Кызыл яшьләр» редакциясендә бүлек мөдире (1934—1937) һәм Татарстан дәүләт нәшриятында редактор (1937) вазифаларын башкара. 1934—1937 елларда, хезмәтеннән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогия институтының тел-әдәбият бүлегендә укый. 1937 елның октябреннән 1957 елның августына кадәр С. Рәфыйков Татарстаннан читтә — төньяк өлкәләрдә һәм Красноярск краенда яши һәм эшли. 1957 елда исә яңадан Татарстанга кайта һәм озак еллар «Социалистик Татарстан» газетасының башта Зәй төбәгендәге үз хәбәрчесе (1958—1961), аннары штаттан тыш хәбәрчесе хезмәтендә була.

С.Рәфыйков 1930 елда яза башлый. 1931—1937 еллар арасында шигырь һәм хикәяләре тупланган өч җыентыгы («Үсү җырлары», «Соңгы талпыну», «Үсмерчак»), сугыштан соң, 1957 елда, «Ак төннәр» исемле шигъри китабы дөнья күрә.

С.Рәфыйков язучы буларак киң җәмәгатьчелеккә «Беренче яз» (1958) романы белән танылa. 1920—1930 еллардагы татар авылында барган социаль үзгәрешләрне, социализм төзү, аерым хуҗалыктан күмәк хуҗалыкка күчү кебек тарихи процессларны шул заманга хас реаль күренешләр һәм образлар аша чагылдырган бу роман алтмышынчы еллар татар прозасының авыл темасына багышланган күренекле әсәрләреннән берсе итеп бәяләнә. Әдипнең колхозларны эреләндерү темасын үзәккә алып, авыл хуҗалыгы белән җитәкчелек, массаларның хезмәттә һәм иҗтимагый тормышта активлыгы, интернациональ бердәмлеге мәсьәләләрен яктырткан «Авыл иртәсе» исемле икенче романы да укучылар тарафыннан җылы каршы алына. Автор гомеренең соңгы елларында Зәй гидроэлектростанциясе төзелешенә багышланган «Тын елга буенда» исемле яңа роман өстендә эшләде. Әсәр әүвәл «Казан утлары» журналында (1971 ел, 2—6 саннар) дөнья күреп, соңыннан, автор вафатыннан соң, Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыкты.



С. Рәфыйков 1971 елның 21 ноябрендә Татарстанның Яңа Зәй эшчеләр поселогында вафат булды.



Бари Рәхмәт
(1897 – 1957)

Татар совет балалар поэзиясенең күренекле вәкиле Бари Рәхмәт (Бари Сибгатулла улы Рәхмәтуллин) 1897 елның 29 маенда элекке Урал губернасының Гурьев өязе (хәзерге Казакъстан ССРның Гурьев өлкәсе) Җилая Коса дигән поселогында хезмәткәр гаиләсендә туа. Башлангыч белемне шул поселоктагы мәдрәсәдә ала. Кечкенәдән үк Г. Тукай әсәрләрен яратып укый, үзе дә яшерен генә шигырьләр языштыргалый. 1914 елда Казанда чыга торган балалар журналы «Ак юл»да (1913—1918) яшүсмер егетнең «Бәйрәм котлы булсын» исемле беренче шигыре дөнья күрә. Шул вакыттан башлап Б. Рәхмәт бу журналның даими авторларыннан берсенә әйләнә.

Бөек Октябрь революциясеннән соң Б.Рәхмәт, Кызыл Армия сафларына алынып, 1918—1921 елларда Казандагы татар запасной батальонында хезмәт итә, 1919 елдан Үзәк мөселман хәрби коллегиясе органы «Кызыл Армия» газетасы редакциясенә күчерелеп, анда әдәби бүлекне җитәкли. Бер үк вакытта ул иҗат эшен дә ташламый, үзе хезмәт иткән «Кызыл Армия» газетасында һәм шул елларда Казанда чыккан башка матбугат органнарында («Эш», «Эшче», «Кызыл Шәрекъ») революцион көрәш пафосы белән сугарылган патриотик шигырьләрен һәм үткен сатирик әсәрләрен бастыра.



1921 елда армия сафыннан демобилизацияләнгәч, Б.Рәхмәт туган якларына кайта һәм 1932 елга кадәр шунда яши. 1932 елда гаиләсе белән бөтенләй Казанга күчеп килеп, төзү трестларының берсендә гади эшче, соңыннан бухгалтер булып эшли. Озак кына вакыт язмый торганнан соң, 1939 елдан башлап, «Чаян» һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналларында аның сатирик һәм лирик шигырьләре яңадан күренә башлый.

Бөек Ватан сугышы башлангач, 1942 елда, Б.Рәхмәт фронтка китә, Украинада, Молдавиядә, Болгария һәм Венгрия җирләрендә барган сугыш-ларда катнаша, 1945 елның февралендә яраланып, госпитальдә ятып чыга, аннан шул елның җәенә кадәр 3 нче Украина фронты газетасы «Совет сугышчысы» редакциясендә хәрби корреспондент булып хезмәт итә.

Шагыйрьнең сугыш чоры лирикасында һәм сугыштан соң олылар өчен язган әсәрләрендә иҗатының нигезендә яткан халыкчан табигыйлек, нечкә юмор белән сугарылган шигъри фикерләү һәм тасвирлау үзенчәлекләре тагы да ачыларак төшә. Аның «Исән булсак, бетмәбез» (1943), «Без кайтырга чыктык» (1945), «Сугыш беткәч» (1945), «Бармагыңа акча түлим» (1946), «Әби белән бабушка» (1949), «Тәмәкене ничек ташларга» (1955) кебек лирик һәм юмористик шигырьләре шул чор татар поэзиясенең матур үрнәкләре булып санала. Шагыйрьнең лирик, юмористик һәм сатирик шигырьләренең шактый зур өлеше 1957 елда басылып чыккан «Шигырьләр» исемле җыентыгында урын алган.

Илленче еллардан башлап Бари Рәхмәт үзенең бай тормыш тәҗрибәсен һәм шигъри талантын яшь буынны — балаларны тәрбияләүгә багышлый. 1949 елда аның кече яшьтәге балалар өчен махсус язылган «Кем көчле» һәм «Укыйсым килә» исемле ике китабы басылып чыга. Шуннан соңгы кыска гына вакыт эчендә (1950—1957) янә алты җыентыгы дөнья күреп, Б.Рәхмәт тиз арада балаларның иң яратып укыла торган язучысына әверелә.

Б.Рәхмәтнең балалар өчен язган шигырьләре тематик байлыгы, форма җыйнаклыгы, фикер һәм хисләренең нәниләр табигатенә ярашлы, эмоциональ көчле яңгырашта булулары белән җәлеп итәләр.

Бари Рәхмәт үзенең шигъри сәләте тәмам ачылып җиткәндә, 1957 елның 26 маенда кинәт вафат булды.

***Чәчәкләрне үп син***

*Күзләреңне тутырып, әби җаным,*
*Кемне эзлисең син, карыйсың?*
*Хәтерләтә синең карауларың*
*Канлы сугышларның тарихын.*
*Әйт, син, әби, кемне карыйсың?*
*“Кайтмас микән йөрәк парәм”, - димсең?*
*Кайтмый, әби, көтмә балаңны.*
*Эзлә гөл, чәчәкләр арасыннан*
*Күз алмаңны, йөрәк парәңне,*
*Йөрәгеңнән тамган балаңны.*
*Суырып-суырып, чәчәкләрне үп син,*
*Күзләре күк күреп бәгъреңнең,*
*Яшьләреңне чәчәкләргә түк син,*
*Искә төшереп ташын каберенең,*
*Кабере кебек күреп бәгъреңнең.*
*Сугарылган каннар, яшьләр белән*
*Нәфис тамырлары аларның.*
*Җир-әнкәйнең кайнар яше белән,*
*Каны белән герой балаңның,*
*Балаң төсе ит син аларны.*
*1945.*



# Мөхәммәт Садри

(1913 – 1999)



Мәхәммәт Садри 1913 елда Казанда туа. Кече яшьтән ятим калып, әүвәл - әбисендә, аннары балалар йортында тәрбияләнә. ФЗӨ мәктәбен тәмамлагач, заводта слесарь булып эшли. Мәскәүдә театр институтында югары белем ала. Шуннан соң Татарстан Министрлар Советының Сәнгать эшләре идарәсендә фәнни эш белән шөгыльләнә.

Бөек Ватан сугышында катнаша. Аннан кайткач, башта – Татарстан Язучылар берлеге идарәсендә, аннары “Кызыл Татарстан” газетасы редакциясендә эшли. М.Садри ФЗӨ мәктәбендә укыган елларда яза башлый. Беренче шигъри җыентыгы 1932 елда дөнья күрә. Хәзерге вакытта аның ике дистәгә якын җыентыгы бар. 50гә якын шигыренә күренекле композиторлар көй язган.

Шагыйрь очерклар, аерым язучылар иҗаты турында тәнкыйть мәкаләләре дә язды, рус һәм тугандаш халыклар әдәбияты вәкилләренең шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итте.

Мөхәммәт Садри 1999 елда вафат булды.



Сирин

(1896 – 1970)



Сирин (Сирин Хәниф улы Батыршин) 1896 елның 14 декабрендә Татарстан АССРның хәзерге Баулы .районы Кәрәкәшле авылында крестьян гаиләсендә туа. революциягә кадәр Бәйрәкә мәдрәсәсен тәмамлый, аннары туган як авылларында башлангыч мәктәпләрдә Далалар укыта. Октябрь революциясеннән соң аны Бөгелмәдәге өч еллык педагогия курсларына укырга җибәрәләр. Шушы елларда Бөгелмәдә чыккан «Юксыл» газетасында ул беренче шигырьләрен бастыра.

1921 елда курсларны тәмамлап, Сирин Казанга юл тота, анда әдәбият-сәнгать кешеләре белән аралаша һәм үзенең иҗади тәҗрибәләрен дәвам иттерә. 1926 елда Бөгелмәдә чыккан «Сабанчы» газетасында бераз вакыт эшләп килгәч, Сирин 1927 елда Казандагы Көнчыгыш педагогия институтына укырга керә һәм, аны уңышлы тәмамлап чыкканнан соң, шактый еллар Казан мәктәпләрендә тел-әдәбият укыта.

1929 елда шагыйрьнең балаларга атап язган «Яз», «Җәй», «Көз», «Кыш» дигән шигырьләре, рәсемнәр белән бизәлеп, аерым-аерым китапчыклар булып басылып чыга, ә 1931 елда «Тамчылар» исемле җыентыгы дөнья күрә.

Шагыйрьнең тормыш, табигать күренешләрен, күмәк хезмәт шатлыгын җанландырып гәүдәләндергән шигырьләре үзләренең оптимистик эчтәлекләре, форма һәм тел-сурәтләү чараларындагы яңалыклары белән укучылар күңеленә бик хуш килә: аларны ятлыйлар, сәхнәләрдән сөйлиләр, мәктәп хрестоматияләренә урнаштыралар, кайберләре (мәсәлән, «Язгы тамчылар» шигыре) композиторлар тарафыннан музыкага салына.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Сирин фронтка китә, берничә тапкыр 1саты яралана. Сугыштан соң туган авылына кайтып, колхозда эшли, сирәк €улса да, шигырьләр яза. Озак һәм каты авырудан соң, ул 1970 елның январь аенда вафат була.



Сәхаб Урайский
(1907 – 1957)

Сәхаб Урайский (Сәхабетдин Камалетдин улы Мәүлютов) 1907 елның 21 декабрендә элекке Самара губернасы Мәләкәс өязе (хәзерге Ульянов өлкәсенең Иске Майна районы) Иске Кызылсу (Татарское Урайкино) авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Яшьле ятим калып, бала чактан ук тормышның ачысын татып үсә: тамак ялы өчен авыл байларында батрак булып эшли, көтү көтә. Бөек Октябрь революциясеннән соң гына, мәктәп партасына утырып, башлангыч белем ала һәм 1927—1930 елларда Самара (хәзерге Куйбышев), шәһәрендәге татар-башкорт педагогия техникумында укый. Аны тәмамлагач, ике ел Урта Идел буе татар совет-партия мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта, ә 1932—1938 ел» ларда Куйбышевта татар телендә чыга торган «Колхозчы» исемле өлкә газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. Шул ук елларда (1934—1936) ул СССР Язучылар союзы һәм комсомолның Үзәк Комитеты каршында ачылган әдәби курсларда укып кайта.

1938 елда Сәхаб Урайский Казанга килә һәм «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасы редакциясендә эшли башлый. 1941—1945 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә һәм, автотранспорт батальонының политик җитәкчесе буларак, сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, медальләр белән бүләкләнә.

Армиядән кайткач, Сәхаб Урайский 1946—1948 елларда республика партия мәктәбендә укый, аннан соң күп еллар буе «Яшь сталинчы» газетасында әдәби хезмәткәр һәм Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә редактор булып эшли.



Сәхаб Урайскийның исеме матбугатта 1929 елдан күренә башлый. Әдәбияттагы беренче адымнарыннан ук ул комсомол шагыйре, яшьләр темасына язучы әдип буларак мәйданга чыга. Лирик-публицистик шигырьләрендә булсын, «Давыллар аша», «Порт-шәһәр» кебек поэмаларында булсын, шагыйрь совет яшьләренең хезмәттәге батырлыкларын, якты идеалларын, өметләрен чагылдырырга омтыла. Иҗатының соңгы дәверендә шагыйрь, риторикадан котыла барып, халыкчан рухтагы һәм үзенчәлекле образларга бай шигырьләр иҗат итә. Аның шигъри табышлары бигрәк тә җыр өлкәсенә карый. Балалар өчен язылган «Пионерлар җыры» (Х. Вәлиуллин музыкасы), «Чыршы янында» (Й. Шәмсетдинов музыкасы), «Укырга» (С .Сәйдәшев музыкасы), шулай ук яшьләргә багышланган «Икебез ике якта», «Безнең яшьләр», «Тау кызы» (Ш Мәҗитов музыкасы), «Син кал бездә», «Онытма» (Р. Яхин музыкасы), «Өй артында шомыртым» (халык көе) кебек җырлар үз заманында халык арасында киң популярлык казана. Ә шагыйрьнең «Син кайтмадың» (М. Мозаффаров музыкасы) җыры Бөек Ватан сугышына багышланган иң гүзәл җырларның берсе буларак тәкъдир ителә.



Әхмәт Фәйзи

(1903 – 1958)



Әхмәт Әхмәтсафа улы Фәйзуллин 1903 елның 11 мартында Уфа шәһәрендә дөньяга килә. Башта Әхмәт мәдрәсәдә (1911—1915) укый, аннары Уфадагы рус» татар мәктәбендә (1915—1917) һәм революциядән соң, 1917—1921 елларда, татар гимназиясендә (урта мәктәптә) белем ала. Мәктәптә һәм гимназиядә укыган елларында үзенең беренче өйрәнчек шигырьләрен һәм пьесаларын яза. Шундыйлардан берсе — «Матурлык дөньясында» (1920) исемле бер пәрдәлек комедия, Уфа, Оренбург сәхнәләрендә куелып, матбугатта уңай бәя ала һәм соңыннан әдипнең томнарына да кертелә.

Урта мәктәпне тәмамлагач, Ә.Фәйзине Оренбургтагы Шәрекъ институтына укырга җибәрәләр. Шунда ул яшь татар язучылары түгәрәге эшенә актив катнаша, беренче тапкыр М.Җәлил белән очраша һәм дуслаша. Ләкин1922 елның декабрендә ул, укуын ташлап, Урта Азиягә китәргә мәҗбүр була һәм 1924 елга кадәр Төркмәнстан кышлакларында һәм шәһәрләрендә укытучы, һәвәскәр театр артисты булып йөри. 1924 елда яңадан Уфага кайтып, уку-һөнәр мәктәбендә (патронатта) сигез ай тәрбияче һәм укыту бүлеге мөдире вазифаларын башкара.

1924 елның ахырыннан башлап, Ә. Фәйзи берничә ел Донбасста татар шахтерлары арасында укыту һәм культура-агарту эшләре алып бара. 1928—1930 елларда Мәскәү, Казан шәһәрләрендә, Татарстанның Арча төбәгендә матбугат һәм мәгариф системасында эшли, ә 1931 елда Мәскәүгә күчеп, шуннан соңгы гомеренең күп өлешен профессиональ язучы сыйфатында башкалада яшәп уздыра.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Ә.Фәйзи Мәскәүдәге Әдәбият институтының өченче курсыннан үзе теләп фронтка китә һәм Волхов, Карелия, Дүртенче Украина фронтларында чыккан газеталарда хәрби корреспондент булып хезмәт итә. Аның иҗат уңышлары поэзия жанры белән бәйле. Ул — татар поэзиясендә интеллектуаль шигырь традицияләрен үстерүгә һәм баетуга күп хезмәт куйган шагыйрь. Аның поэзиясе заман сулышын тирән тойган, социаль яңгырашлы, публицистик рухлы сугышчан поэзия булып формалаша. «Яңа жырлар», «Көрәш бара», «Чор турында җыр», «Эзләр», «Давыл җыры», «Дулкыннар ни сөйлиләр?» кебек җыентыкларындагы лирик һәм публицистик шигырьләрендә, «Өермәләр» (1925), «Миллион Зиннәт» (1927), «Флейталар» (1933), «Дала һәм кеше» (1933), «Кара таш ник дәшми» (1940), «Туу сулышы» (1943) кебек поэмалары һәм балладаларында бу хасиятләр бик ачык төсмерләнәләр. Лирик геройның монологы рәвешендә язылып, социалистик тормыш шартларында яңа кеше туу процессы, аның рухи дөньясындагы каршылыклы эволюцияне, көрәш кискенлеген фәлсәфи тирәнлек, эпик киңлек белән, сәнгатьчә үтемле итеп тасвирлаган «Флейталар» поэмасы гомумән татар совет поэзиясенең утызынчы еллардагы мөһим казанышларыннан берсе булып исәпләнә.

Ә. Фәйзи поэзиясендә юмор-сатира да зур урын били. Мондый төр әсәрләрендә ул, карикатура, пародия, шарж, эпиграмма кебек сатирик  типиклаштыру алымнарыннан оста файдаланып, бюрократлык, кода-кодагыйлык, принципсызлык, мещанлык күренешләреннән усал көлә, фашизм, империализм дөньясын, яңа сугыш ачарга җыенучыларны фаш итә.

Ә.Фәйзи — күп санлы сәхнә әсәрләре авторы. Иҗатының башлангыч чорында ул нигездә кече күләмле, тормышның агымдагы актуаль мәсьәләләренә багышланган, агитацион эчтәлекле пьесалар язу белән мавыга. Әдипнең лҗат мирасында шундый характердагы ике дистәдән артык пьеса бар. Үз вакытында алар Уфа, Оренбург, Мәскәү, Донбасстагы клуб сәхнәләрендә уцыш белән барганнар һәм массаны яңа рухта тәрбияләү эшендә көчле генә сәнгать чарасы булып хезмәт иткәннәр.

Утызынчы еллардан башлап, Ә.Фәйзинең драматургия өлкәсендәге иҗат эшчәнлеге тематик һәм жанр ягыннан тагын да төрлеләнә төшә. Ул күп кенә комедияләр («Каеннар яфрак ярганда», «Беренче елмаю», «Шәмгун Тавысов» һ. б.), сатирик пьесалар («Төтен», «Түрәкәй»), тарихи-биографик драмалар («Тукай», «Пугачев Казанда») иҗат итә, театр сәнгатенең синтетик төрләрен (музыкаль комедия, опера, балет) үзләштерү юлында уңышлы адымнар ясый. 1939 елны Татар дәүләт опера һәм балет театры үзенең беренче сезонын Н.Җиһановның Ә.Фәйзи либреттосына язылган «Качкын» операсы белән ачып җибәрә. Опера Казан, Мәскәү, Ленинград театрларында гына түгел, Франция, Канада кебек чит ил сәхнәләрендә дә зур уңыш казана. Н.Җиһановның «Җәлил», М.Мозаффаровның «Зөлхәбирә» опералары, Р.Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балеты шулай ук Ә.Фәйзи либреттосына таянып язылганнар. Ватан сугышы чорында әдип композитор Җәүдәт Фәйзи белән иҗади берлектә «Акчарлаклар» исемле музыкаль комедиясен (беренче вариантын) тәмамлый, ә 1947 елда аны театр өчен яңабаштан үзгәртеп эшли.

Сугыштан соңгы елларда Ә.Фәйзи, драматургия өлкәсендәге эзләнүләрен дәвам итеп, әхлак мәсьәләләренә багышланган «Отышлы кияү» (1947), «Күршеләр» (1951), «Сәйдә апа» (1955) комедияләрен һәм «Рәүфә» (1957) исемле психологик драмасын яза.
Театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ә. Фәйзи Татарстан АССРньщ (1953) һәм РСФСРның (1957) атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә лаек була.

Ә.Фәйзинең сугыштан соңгы иҗатында «Тукай» романы үзенә аерым урын били. Ике китап итеп уйланылган бу эпопеяне әдип 1947 елда яза башлый һәм беренче китабын 1950 елда тәмамлый. Шул ук елны роман «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында, ә 1952 елны Казанда аерым басма булып чыга. 1956 елда әсәрнең автор тарафыннан төзәтелгән икенче басмасы дөнья күрә. Тиз арада ул русчага тәрҗемә ителеп» берничә

***Бүләк***

*Бу зур бүләк түгел, дустым, сиңа,*
*Әмма монда бик зур теләк бар.*
*Бу бүләктә сине сөеп көткән,*
*Сине сагынып типкән йөрәк бар.*
*Бу бүләктә безнең мәхәббәтнең*
*Сиңа булган иң-иң олысы.*
*Бу бүләктә мең-мең йөрәк җыры,*
*Миллион күңелләрнең җылысы.*
*Бу бүләктә батыр сугышчыга*
*Иң зур хөрмәт, иң зур игътибар.*
*Бу бүләктә безнең егетләрнең*
*Син кабызган җиңү дәрте бар...*
*Бу бүләкне юллый ил кызлары*
*Сине сөю белән кабынып, -*
*Алар юллый моны синең тизрәк*
*Җиңеп кайтуыңны сагынып.*
*Бу бүләктә сиңа төбәлгән, дус,*
*Безнең балаларның өмете...*
*Тик син генә хаклы бу бүләккә,*
*Совет иленең герой егете!*
*1942.*

Бу шигырь, күпләп бастырылып, фронтка җибәрелә торган посылкалар эченә салына.

Ә. Фәйзи — әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть, публицистика өлкәсендә бай мирас калдырган язучыларның берсе («Әдипнең эрудициясе» җыентыгы, 1973). Ул шулай ук сатирик хикәяләр («Каен себеркесе» җыентыгы, 1958), киносценарийлар («Тукай», «Тарих рычагы», «Пәйгамбәр Әюп һәм итекче Сафа», «Совет Татарстаны» һ. б.), балалар өчен тезмә һәм чәчмә әсәрләр («Бал корты», «Ак аю», «Тискәре Ишми», «Аучы Мәргән белән Болан кыз әкияте» Һ. б.) һәм әдәби тәрҗемәләр авторы буларак та билгеле. Аерым алганда, әдип А. Пушкинның «Борис Годунов» трагедиясен (1937), «Братья Разбойники» («Юлбасар туганнар», 1937) поэмасын, Н. Гогольнең «Тарас Бульба» повестен (1953), Т. Шевченко, В. Маяковский, А. Барто һәм башка Шагыйрьләрнең күп кенә әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итте.

Татарстан китап нәшрияты 1983 елдан әдипнең биш томлык сайланма әсәрләр җыелмасын чыгара башлады.



Сибгат Хәким

(1911 – 1986)



Сибгат Таҗи улы Хәкимов 1911 елның 4 декабрендә Татарстанның Арча районы Күлле-Киме авылында туган. Үз авылында жиде класс тәмамлагач, берникадәр вакыт мәктәптә пионервожатый булып эшли. 1931 елда Казанга килеп, «Татрабфак»ка укырга керә. Икенче курстан аны Казан дәүләт педагогия институтына күчерәләр. 1937 елда институтның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем алып чыккач, С.Хәким Ватан сугышына кадәр Татарстан дәүләт нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты секторында редактор (1937—1938) һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр (1938—1941) булып эшли.

1941 елның июнендә С. Хәким армиягә алына. Шул елның ахырына кадәр запастагы гаскәри частьтә хезмәт итә, аннары кыска сроклы хәрби курсларда укый. 1942 елның маеннан ул хәрәкәттәге армиядә: әүвәл укчы взвод, соңыннан рота командиры сыйфатында Ржев тирәсендә һәм Курск дугасында барган каты сугышларда катнаша, фронтта күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены (1943) һәм медальләр белән бүләкләнә. 1944 елның язында Саратов шәһәрендә хәрби-политик курсларны тәмамлаганнан соң, С. Хәким 1946 елның маена кадәр Молдавиядә чик буе гаскәрләренең округ политик идарәсе органы «Пограничник Молдавии» газетасында инструктор булып хезмәт итә.

Армиядән демобилизацияләнеп кайткач, 1946—1950 елларда С. Хәким «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр һәм бүлек мөдире булып эшли. 1950 елдан бирле ул, нигездә, профессиональ язучылык хезмәтендә.

С. Хәким — халык иҗаты, халык җырлары һәм Тукай поэзиясе традицияләре җирлегендә яза башлаган шагыйрьләрнең берсе. Аның беренче шигырьләре утызынчы еллар башында «Атака», «Совет әдәбияты» журналлары һәм «Кызыл яшьләр» газетасы битләрендә дөнья күрә, сугышка кадәр лирик шигырьләре тупланган «Беренче җырлар» исемле китабы һәм шигъри остазы Г. Тукайга багышланган «Пар ат» (1938—1939), «Шагыйрьнең бала чагы» (1940) исемле поэмалары басылып чыга. Гомумән, Тукай образы, Тукай темасы шагыйрь иҗатында зур урын алып тора. Алтмышынчы-җитмешенче елларla, мәсәлән, бу темага ул махсус шигъри цикл («Тукай дәфтәре») һәм «Кырыгынчы бүлмә» (1971) исемле мәгълүм поэмасын иҗат итә. Тукай шәхесе, Тукай традицияләре турында уйланулар әдипнең публицистик мәкаләләрендә, әдәби эссе һәм парчаларында да төп темаларның берсен били.

С. Хәкимнең башлангыч чор иҗатында, аерым алганда, беренче поэмаларында төсмерләнгән поэтик фикерләү һәм язу стиленең хасиятләре—нечкә лиризм^ хис-тойгы колачлыгы, халыкчан образлылык, шигъри формадагы төгәллек, пөхтәлек алга таба тагы да камилләшә, яңа сыйфатлар белән тулылана һәм сугыштан соңгы елларда ил һәм дөнья күләмендә барган бөек Үзгәрешләрнең тарихи мәгънәсен шигъри образларда калку итеп гәүдәләндергән олы хисле, тирән фикерле, гуманистик рухлы поэзия булып формалаша.

Ватан сугышы шагыйрьнең гуманистик тойгыларын, патриотик хисләрен тирәнәйтүгә, гражданин-шәхес буларак чыныгуына, җитлегүенә хәлиткеч йогынты ясый. Сугыш темасы аның бөтен иҗаты буенча кызыл җеп булып сузыла. Бу олы тема эпик колачлыгы һәм фәлсәфи тирәнлеге белән «Курск Дугасы» (1948), «Дала җыры» (1948), «Бакчачылар» (1952), «Дуга» (1968) һәм «Күги» (1983) кебек поэмаларында аеруча калку гәүдәләнә. Бу эпик исәрләрендә автор, сугыш кырындагы баталь күренешләрне җанландырып күрсәтү, геройларының драматик язмышларын сурәтләүдән тыш, кеше һәм сугыш, кешелеклелек, халык батырлыгы кебек фәлсәфи мәсьәләләрне күтәрә һәм геройларының язмышлары турындагы кырыс хикәяне халык, дөнья язмышы турындагы уйланулары, фәлсәфи фикерләре белән үреп бирә. Шушы ук хасиятләр, дөнья турында борчылып уйланулар, сугышка каршы нәфрәт хисләре, тынычлык өчен көрәш пафосы шагыйрьнең «Торыгыз, Мусалар!», «Немец дәфтәреннән» исемле шигъри цикллары һәм «Эзлиләр Европа буйлап» (1981) исемле поэмасы өчен дә характерлы.

***Иртән***

*Кичтән янган учак көйрәп ята,*
*Йөк атлары йөри тукланып;*
*Кем дөньяга килгән серле таң бу?*
*Күзем алмый торам сокланып.*
*Үләннәргә салкын чык утырган,*
*Күтәрелә томан болыннан;*
*Рота йоклый. Ике автоматчы*
*Алып килә басу юлыннан*
*Бер немецны полк штабына,*
*Тынып калган көньяк даласы,*
*Арган, ахры, төнге сугыштан соң*
*Җир селкеткән “сугыш алласы”.*
*Күзләремә минем йокы керми,*
*Кузгалдык без моннан сәфәргә;*
*Шушы таңга карап, солдатларым*
*Горур атлап бара яшәргә.*

*1943.*

Шагыйрь игътибарын даими биләп торган мөһим темаларның тагын берсе— туган җир. Үзе туып үскән Казан арты төбәгенә, аның табигатенә, кешеләренә мәхәббәт хисе шагыйрьнең бөтен иҗатын озатып бара. Бу тема әдипнең күп санлы лирик шигырьләрендә, җырларында, «Үрләр аша» (1964), «Васыятьләр» (1969), «Дәверләр капкасы» (1974) кебек поэмаларында чагылыш таба.

Туган як темасына бәйле рәвештә С.Хәким иҗатында В.И.Ленинга багышланган әсәрләр үзенә аерым урын алып тора. Аның Ленин турындагы беренче шигыре әле 1938 елда ук языла («Кышкы салкын иде...»). Күп еллар үткәч, шагыйрь Ленин темасына яңадан әйләнеп кайта һәм юлбашчы образың татар халкының язмышына бәйләп, Татарстан материалы җирлегендә сурәтләргә керешә. «Күңелем Ленин белән сөйләшә» (1957) җыры, «Ленин фәрманы белән» (1958), «Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты» (1961), «Баһавиның моңы» (1963), «Язылгыз, җир уллары!» (1963) поэмалары татар совет поэзиясендә Лениниананың уңышлы үрнәкләре булып саналалар.

Русча тәрҗемәдә чыккан «По зову Ленина» («Ленин фәрманы белән») исемле поэма һәм шигырьләр җыентыгы һәм татар телендәге «Җил исми яфрак селкенми» (җырлар, поэмалар) китабы өчен С.Хәким 1960 елда Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, ә 1970 елда Ленин турындагы әсәрләр циклы һәм яңа шигырьләре өчен РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

С.Хәким — дистәләгән җырлар авторы. «Юксыну» (Ш.Мәҗитов музыкасы), «Фазыл чишмәсе», «Таң атканда» (халык көйләре), «Күңелем Ленин белән сөйләшә» (Х.Вәлиуллин музыкасы), «Башка берни дә кирәкми», «Кайда да йөрәктә» (М. Мозаффаров музыкасы), «Өзелгәнсең сиреньнән» (Н. Җиһа-нов музыкасы), «Бу кырлар, бу үзәннәрдә», «Кем уйлаган» (Җ. Фәйзи музыкасы), «Бер тауда ун чишмә» (Ә. Фәттах музыкасы) кебек җырлар халык арасында зур популярлык казандылар.

С.Хәкимнең әдәби процесс турында, каләмдәшләренең, сәнгать кешеләренең — композиторларның, актерларның, җырчыларның иҗаты турында, язучы осталыгы, традицияләрне үстерү, яңарту проблемалары турында язган мәкаләләре, истәлек-уйланулары, лирик парчалары да зур игътибарга лаек. Шагыйрьнең бу төр хезмәтләре, бергә тупланып, 1979 елда аерым китап булып басылып чыкты («Халык язмышы — шагыйрь язмышы»).

С.Хәким олы шагыйрь исемен актив җәмәгать эше белән бәйләп бара. Ул КПССның Татарстан Өлкә комитеты члены (1968—1971), Татарстан Верховный Советы депутаты (1963—1967), Казан шәһәр Советы башкарма комитеты депутаты (1955—1957) булды, Татарстан АССР Верховный Судында халык утырышчысы хезмәтен башкарды (1954—1958). Ул—1954 елдан бирле Татарстан Язучылар союзы идарәсе члены, 1954—1958 елларда идарә председателенең урынбасары булып эшләде. РСФСР язучыларының икенче съездында РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре итеп сайланды. Ул шулай ук күп еллардан бирле Татарстан Язучылар союзы каршындагы Кабул итү комиссиясенә җитәкчелек итә, «Казан утлары» журналы редколлегиясе составында зур җәмәгать эшләре алып барды.



Мәхмүт Хөсәен
(1923 – 1993)

Мәхмүт Хөсәен (Мәхмүт Хафиз улы Хөсәенов) 1923 елның 15 апрелендә хәзерге Казакъстан ССРның Көнбатыш Казакъстан өлкәсе Җаңакала районы Урда авылында эшче гаиләсендә туган. 1941 елда Петропавел (Кызылъяр) шәһәрендә татар урта мәктәбен тәмамлагапнан соң, берникадәр вакыт пионервожатый, «Ленинское знамя» газетасында әдәби хезмәткәр, «Экпенды» промартелендә культмассовик булып эшли. Бөек Ватан сугышы башлангач, М. Хөсәен үзе теләп армия сафларына баса. 1942 елда Әндиҗан шәһәрендә кыска сроклы артиллерия училищесын тәмамлаганнан соң, 1943 елның январеннан алып 1944 елның декабренә кадәр башта взвод, соңыннан артиллерия батареясе командиры сыйфатында фронтның алгы сызыгында сугыша, канлы бәрелешләрдә катнаша, берничә тапкыр яралана, шәхси батырлыклары өчен Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә. 1945 елда Ленинградта Югары Артиллерия мәктәбендә укый, аннары 1947 елның июненә кадәр Ленинградта һәм Казанда командир булып хезмәт итә.

1947—1952 елларда М.Хөсәен — Казан дәүләт университеты студенты. Университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, ул озак еллар Татарстан китап нәшриятында башта редактор (1952—1954), аннары матур әдәбият редакциясе мөдире (1954—1957) һәм өлкән редактор (1957—1975) булып эшли. 1976 елдан — язучы-профессионал, әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.



М.Хөсәен мәктәптә укыганда ук әдәбият белән кызыксына һәм шигырьләр яза. Беренче шигъри тәҗрибәләре сугышка кадәр «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналы битләрендә басыла. Бөек Ватан сугышы чорында патриотик эчтәлекле күп кенә шигырьләре фронт газеталарында («Ватан сагында», «Кызыл Армия», «Суворовчы» һ. б.) урын ала. Яшь шагыйрьнең беренче шигъри тупланмасы да («Туган ил өчен») бөек җиңү яулаган елны Ленинград хәрби нәшриятында дөнья күрә.



# Гали Хуҗи

(1912 – 1966)



Гали Хуҗи Татарстанның Апас районы Карамасар авылында туа. 1937-1941 елларда, эштән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогика институтының кичке бүлегендә укый, 1932-1934 елларда “Кызылармеец” газетасында - әдәби хезмәткәр, 1934 елдан – “Яшь ленинчы” газетасының җаваплы сәркатибе, соңрак редактор урынбасары һәм редакторы була. Үзе теләп сугышка китә һәм фронт газетасында җаваплы сәркатип булып хезмәт итә.

Гали Хуҗи әдәбиятка утызынчы елларда килә. Аның “Шатлык” исемле беренче шигъри җыентыгы 1936 елда басылып чыга. Шуннан соң дистәләрчә китаплары (“Яшьлек тавышы”, “Комсомолка”, “Сабан тургайлары”, “Зоя”, “Туган җир”, “Чын күңелдән”, “Мин сөям сезне, дуслар!”, “Кояшлы иртә”, “Идел хикәясе” һ.б.) дөнья күрә.

1966 елның 13 октябрендә вафат була.

*Солдат булып кулга корал алдым,*
*Куркынычта илем язмышы, -*
*һәр кайгыдан естен шушы кайгым,*
*һәр кайгыдан авыр һәм ачы.*

*"Туган жир"*



## Самат Шакир

(1924 – 1998)

Самат Шакир (Самат Фәтхерахман улы Шакиров) 1924 елның 15 апрелендә Татарстанның Арча районы Күәм авылында туган. Җиде классны тәмамлагач Арча педагогия училищесында укый, аннары Носы авылы мәктәбендә укытучы, Әтнә район газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр һәм 1942—1943 елларда Янавыл мәктәбендә янәдән укытучы һәм мәктәп мөдире булып эшли. 1943—1945 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. Армиядән кайткач, бераз вакыт «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, аннан соң, 1946— 1949 елларда, Дөбъяз районы газетасының җаваплы секретаре була.

1951 елда С. Шакир В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый башлый. Бер елдан читтән торып уку бүлегенә күчеп, Чүриле районының Сикертән авылы мәктәбенә укытучы булып китә. 1954 елда Татарстан Мәгариф министрлыгы аны Кайбыч районы Мөрәле мәктәбенә директор итеп җибәрә. 1958—1962 елларда С. Шакир Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли. 1957 елда, читтән торып укып, университетны тәмамлый. Ул—1953 елдан КПСС члены.



Самат Шакир әдәби иҗат эшчәнлеген шигырь язудан башлый. 1939 елда «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналында «Урман» дигән беренче шигыре басылып чыга. Шуннан бирле аның мәктәп тормышы, туган табигать, гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы темаларына багышланган һәм, нигездә, мәктәп балаларына атап язылган күпләгән шигырьләре көндәлек матбугатта да, аерым җыентыклар булып та бик еш басыла. Ул — уннан артык поэтик китап авторы. 1984 елда әдипнең иң яхшы поэтик әсәрләре тупланган «Яраннар чәчәк

Шулай да, Самат Шакирның иҗади йөзен, поэзиядән бигрәк, проза әсәрләре — очерклары, документаль повестьлары билгели. Аның яраткан темасы — Бөек Ватан сугышы. Автор күп йөри, эзләнә, дәһшәтле сугыш булган урыннарга бара, архивларда казына, сугыш ветераннары — карт солдатлар, элекке партизаннар, хәрби начальниклар белән очраша. Әнә шулай үзенең хәрби-патриотик темага багышланган әсәрләре өчен документаль материаллар җыя. Аның 1965 елда басылып чыккан «Легенда егетләре» исемле беренче документаль повесте аеруча уңыш казана. Сталинград өчен сугышларда батырларча һәлак булган өч егет—испан егете, капитан Рубен Ибаррури Руис, рус егете, очучы-майор Владимир Каменщиков, татар егете, артиллерист-капитан Хафиз Фәттәхетдинов турындагы әлеге китап соңыннан рус, төрекмән, казакъ телләренә тәрҗемә ителә. Язучының легендар панфи-ловчылар турындагы «Үлемсезләр» китабы, бер төркем Советлар Союзы Геройларына багышланган «Һәйкәлләр итәгендә чәчәкләр» документаль повесте («Казан утлары» 1976, № 10), «Ташлардагы язулар», «Үлемне җиңгән батыр», «Исемнәре мәрмәрдә» кебек очерк китаплары укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан уңай каршы алына.




Язучы Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына кагылышлы документаль материалларны эзләп табу, аларны матбугатка әзерләп чыгару буенча нәтиҗәле эш алып бара. Ул, татар шагыйре Хәйретдин Мөҗәйнең фронт көндәлекләрен һәм шигырьләрен эзләп табып, аерым китап итеп бастырып чыгарды, язучының тормышы һәм иҗаты турында очерк язды. Шулай ук ул — «Сугыш язмалары» (1967), «Солдат хатлары» (1968), Ватан сугышы кырларында һәлак булган егерме тугыз татар совет язучысының әсәрләрен, биографик белешмәләрен үз эченә алган «Алар сафта» (1961) җыентыкларының авторы-төзүчесе.

С. Шакир, журналист буларак, Куйбышев, Братск, Красноярск ГЭСлары, КамАЗ һәм БАМ төзелешләрендә булып кайта, Казакъстанда чирәм җирләрне күтәрүдә катнаша, һәм алар турында үзенең язмаларын, очеркларын бастыра. Җәмәгать һәм язучылык эшчәнлеге өчен аңа 1984 елның апрелендә Татарстан АССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде.



# Әхмәт Юныс

(1916 – 1976)

Әхмәт Юныс 1916 елда Татарстанның Кукмара районы Әсән Елга авылында туа. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, башлангыч сыйныфларда – укытучы, 1937 елда Казанга килеп, Татарстан китап нәшриятында – мөхәррир, «Кызыл Татарстан» һәм «Яшь сталинчы» газеталарында әдәби хезмәткәр булып эшли.

Ак финнарга каршы сугышта, аннары Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Казан университетында югары белем ала, «Яшь сталинчы» газетасы һәм «Пионер» журналы редакцияләрендә, Татарстан китап нәшриятында эшли.

Әдәбиятка ул 30 нчы еллар ахырында килә. 1936 елда аның «Гүзәл яшьлек» дигән беренче шигъри җыентыгы басылып чыга. Аннары «Тантана», «Әсән Елга», «Без кайтырбыз», «Уңыш», «Яз килә», «Кырларга сәяхәт», «Көн артыннан көн» һ.б. китаплары дөнья күрә.

Ә.Юныс К.Чуковский, С.Маршак, А.Барто, Я.Коллас шигырьләрен, М.Миршәкәрнең «Ленин Памирда» әсәрен татарчага тәрҗемә итә.



Ә.Юныс, озакка сузылган каты авырудан соң, 1976 елның июлендә Казанда вафат була.



## Кулланылган әдәбият


- Җыр һаман яңгырый. Төзүчеләре: Кәримуллин А. Г., Юзеев Н.Г. - Казан, Таткнигоиздат, 1956.
- Мостафин Р.Ә. Җәлилчеләр: очерклар, җәлилчеләр иҗаты. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1988.
- Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясе: шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2005.
- Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. 5 нче том: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941 – 1960). – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1989